СИМЕЗ БУЛСЫН!

Көч куеп үстергән мал-туарны урнаштыру авыл халкы өчен зур эш булып тора

> 5

ЯВА КАРЛАР

Яңа кышның – иске мәшәкате. Юлларны кем тәртиптә тота?

> 7

МӘДИНӘ МАЛИКОВА:

«Язучылар арасында мин хәлләрдән саналам»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 181 (29148) | Җомга | 8 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

pxhere.com

ГАЗ КУЫГЫ

ЯҢА КИЛЕШҮНЕ ТӨЗЕРГӘ ВАКЫТ БИРДЕЛӘР

«2024 елның 1 гыйнварына кадәр газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү турындагы килешүне яңадан төзергә кирәк. Югыйсә 40–100 мең сумга кадәр штраф яный...» Бу атнада туган-тумача, күрше-күлән арасында таралган әнә шундый әчтәлектәге хәбәрләр күпләрнең төн йокысын качырды. Алай гына да түгел, республикадагы газ оешмаларында озын чиратлар хасил булды. Штрафлар белән куркыткан газчыларны Татарстан Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы вәкилләренә тынычландырырга туры килде хәтта. Газ килешүен кайчан төзергә? Мәсьәләгә «ВТ» хәбәрчесе ачыклык кертте.

> 6

Ишетми калмагыз

Россия Президентын сайлау киләсе елның 17 мартында үткәреләчәк. Федерация Советы утырышында шундый карар кабул ителде.
Дәүләт башлыгы Владимир Путин 2024 елда Президент сайлавында катнашачагы турында рәсми төстә белдермәде әле. Конституция нигезендә, аның өченче срокка сайлануга хокукы бар. Президент моңа кадәр әйткәнчә, мондый мөмкинлек партия эчендәге вазгыятьне тотрыкландыру мөмкинлеге бирә.
Россия Президентын сайлау өч көнгә сузылырга мөмкин. Үзәк сайлау комиссиясе өч көнлек тавыш бирү турындагы карарны раслаган очракта, сайлау 15, 16 һәм 17 мартта үткәреләчәк.

Камал театрының яңа бинасы мәйданы 48,8 мең кв. м тәшкил итәргә тиеш. Театр проектына үзгәрешләрдән (Казан башкарма комитетының документлар һәм хокукый актлар җыентыгында басылып чыккан) күренгәнчә, бина 1370 урынга исәпләнгән. Театр территориясе 3,15 гектар мәйданны алып торачак.
5–8 катлы бинада барлыгы 4 зал булдырылачак. Зур зал – 788 урынга, кечкенә зал (түгәрәк) – 242, универсаль – 300гә кадәр (урыннар саны сценографиягә карап үзгәрергә мөмкин) һәм кечкенә зал 40 урынга исәпләнгән. Театрда барлыгы 544 хезмәткәрнең эшләве күздә тотыла. Театр бинасы бер үк вакытта 788 тамашачыны һәм 210 хезмәткәрне сыйдырачак.

Шимбә – 9 декабрьдә авыл хуҗалыгы ярминкәләре үткәрелмәячәк. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хәбәр иткәнчә, һава шартларына бәйле бу. Зыкы суыкта төп авыл хуҗалыгы продукциясе: яшелчә, сөт, сөт ризыклары өшеячәк чөнки.
Оештыручылар, килеп туган хәлне аңлауны үтенеп, халыкны киләсе ярминкәләрдә көтеп калалар.

Татарстанда бик нык суытты. Тәүлеклек уртача температура нормадан 20 градуска түбәнрәк: –25...–30 градус.
Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, шимбә-якшәмбе – 9–10 декабрьдә республикада явым-төшем көтелми. Төньяк-көнчыгыштан талгын гына җил. Көндез термометрның терекөмеш баганасы –21...–28 градуска кадәр, төнлә –25...–32, урыны белән –33...–38 градуска кадәр төшәчәк. Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, киләсе атна башында – 11–12 декабрьдә дә салкын булачак. Көндез һава температурасы –22...–27 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә –25...–30, урыны белән –32...–37 градус.
Белгечләр әйтүенчә, декабрьнең беренче һәм икенче декадаларында шундый суыклар 2002, 2009 һәм 2012 елларда күзәтелгән.

ЧИКСЕЗ ИПОТЕКА

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ташламалы ипотека программаларын вакыт ягыннан чикләмәскә тәкъдим итте. Бу хакта ул Россия Дәүләт Советының Төзелеш, ТКХ һәм шәһәр мохите буенча комиссиясе һәм Дәүләт Думасының Төзелеш һәм ТКХ буенча комитетының уртак утырышында әйтте. Билгеле булганча, әлеге комиссияне Рөстәм Миңнеханов җитәкли.

tatarstan.ru

– Ташламалы ипотека программалары ярдәмендә халык арасында торак сатып алуга тотрыклы сорау барлыкка килде, – диде ул. – Күреп торабыз, узган ел белән чагыштырганда быелның ун аенда ил күләмендә ипотека кредитлары саны 61 процентка арткан. Тик шунысы бар: төп ставка ике тапкыр күтәрелде, бу исә ипотека ставкалары үсүгә һәм сату-алулар кимүгә китерәчәк. Сентябрь белән чагыштырганда без моны октябрь аенда сиздек инде.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, яңа торак базарыннан фатир сатып алучыларга нәкъ менә ташламалы ипотека программалары ярдәм итә. «Бүген Казанда ике бүлмәле фатирның уртача бәясе 12–13 миллион сум тора. Балалы гаиләләр арасында әнә шундый торакка ихтыяҗ зуррак», – дип тә өстәде ул.

Татарстан Рәисе гаилә һәм ташламалы ипотека программалары буенча иң зур кредит күләмен хәзерге 6 миллионнан 12 миллион сумга кадәр күтәрергә тәкъдим итте. Шулай ук, утырышта катнашкан Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин әйткән фикерне хуплап, гаилә (6%), ташламалы (8%) һәм авыл (3%) ипотекалары буенча процент ставкаларын ничек бар шулай калдырырга кирәклеген белдерде.

– Төбәк башлыклары эшчәнлегенә бәя биргәндә төп билгеләрнең берсе ул – халыкның тормыш шартларын яхшырту. Ипотека кул җитмәскә әйләнсә, без халыкны ничек торак белән тәэмин итәчәкбез? – дип тә өстәде Рөстәм Миңнеханов.

Республика башлыгы фикеренчә, теге яки бу ташламалы ипотеканың тәмамлану вакыты җиткән саен, халык арасында торакка сорау кискен арта. Шуңа күрә дә, мөмкинлекләр булганда, ташламалы ипотека программаларын вакыт ягыннан чикләмәскә тәкъдим итте ул. Авыл ипотекасы кебек, мәсәлән.

Рөстәм Миңнеханов кечкенә торак пунктларда яңа йортлар төзү мәсьәләсенә дә тукталды. Аның әйтүенчә, бу бигрәк тә әлеге җирлекләрдә халык санын саклап калу һәм сәнәгатьне үстерү өчен кирәк.

Торак базарында тәкъдимнәр күбрәк булган саен, бәяләр дә акрынрак үсәчәк, зур шәһәрләргә күченергә теләүчеләр дә азмы-күпме кимеячәк.

– Барлык төбәкләр өчен дә әһәмиятле булган тагын бер юнәлеш – хосусыйлаштыру хокукы булмаган социаль торак төзү, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Мәсәлән, Татарстанда гына да 38600 гаилә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яки әлеге хокукка ия. Шул ук вакытта федераль һәм республика программалары ярдәмендә алар арасыннан ел саен нибары 1 меңе торак белән тәэмин ителә. Бу мәсьәләдә яңа алымнар эзләргә кирәк.

Татарстан Рәисе ТКХ тармагының торышы һәм үсеше мәсьәләсенә дә игътибар итте. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, әлеге тармак халык арасында бик зур ризасызлык уята. «Күпфатирлы йортлар фонды белән идарә итү эшендә дәүләтнең өлешен арттырырга кирәк», – дигән фикер белдерде Рәис. Ул хәзерге вакытта Дәүләт Думасында идарәче компанияләргә лицензия бирүгә үзгәрешләр кертүгә бәйле закон проекты тикшерелүен дә әйтте. Рөстәм Миңнеханов Россия Президенты Владимир Путинга коммуналь инфраструктураны модернизацияләү программасы өчен аерым рәхмәтен җиткерде.

КЕЧКЕНӘДӘН ӨЙРӘТИК

Татарстан Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВНЫҢ Коррупциягә каршы халыкара көрәш көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Ел саен 9 декабрьдә Коррупциягә каршы халыкара көрәш көне билгеләп үтелә. Россия Федерациясендә коррупциягә каршы көрәш бик мөһим дәүләт бурычы булып тора. Хакимиятнең барлык баскычлары һәм тармаклары алдына куелган коррупциягә каршы көрәшкә бәйле бурычлар законнар чыгару эшендә, шулай ук законнарны тормышта куллануда өстенлекле булып тора.

Татарстанда бу юнәлештә зур эшләр башкарыла. Коррупциягә каршы сәясәтнең төп принциплары нигезендә, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының ачыклыгын, «үтә күренмәлелеген» тәэмин итү буенча чаралар уздырыла.

Цифрлаштыру коррупцион күренешләрнең сизелерлек кимүенә ярдәм итә. Бу җәһәттән хакимият органнарының дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча халык белән электрон хезмәттәшлек системасы, «Халык контроле», «Инцидент-менеджмент», сатып алуларның төбәк мәгълүмат системасы югары нәтиҗәләр күрсәтеп килә.

Коррупциягә каршы көрәш – һичшиксез, комплексლы һәм системалы эш. Ул хокук саклау органнары эшчәнлеге нәтиҗәләренә генә кайтып калмый. Җәмгыятьтә коррупциягә каршы аң-фикерне үстерүне дәвам итү чиктән тыш мөһим. Балачактан ук: башта – гаиләдә, шуннан соң мәктәптә һәм югары уку йортларында коррупциягә карата нәфрәт тәрбияләнергә тиеш.

Җәмгыятьтә коррупцияне кабул итмәүнең, битараф калмау, илдәге уңай үзгәрешләргә шәхсән җаваплылык тоюның Россияне уңышлы үстерүнең нигезе булып торуына иманым камил.

БӘРӘКӘТЛЕ ХӘРӘКӘТ

Казанда спортка тотылган чыгымнар турында сөйләштеләр. Федераль казначылыкның тикшерү комиссиясе утырышында «Физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашырганда федераль бюджет чыгымнарының ничек тотылуы хакында фикер алыштылар. Утырышта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Татарстан Рәисе әйтүенчә, республикада физик культура һәм спортны үстерү – өстенлек бирелгән юнәлешләрнең берсе. Соңгы 10 елда Татарстанда 105 эре физик культура һәм спорт объекты төзелде. «2013 елдан безнең шәһәрләрдә һәм районнарда урам спорт мәйданчыклары һәм кече спорт корылмалары төзү буенча республика программасы гамәлгә ашырыла. Бу вакыт эчендә 1153 спорт объекты төзелде», – диде Рөстәм Миңнеханов. Бүген Татарстанда 11,7 мең спорт корылмасы бар.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, республикада башкарылган эш нәтиҗәсендә системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең өлеше 60,9 процентны тәшкил итә. Ел ахырына бу күрсәткеч 61,2 процентка җитәр дип көтелә. «Татарстан Республикасы – илнең спорт иң киң таралган төбәкләреннән берсе, ә Казан спорт башкаласы санала», – диде Татарстан Рәисе.

Россиянең спорт министры Олег Матыцин әйтүенчә, Казан һәм Татарстан спорт чараларын оештыра белә, шуңа күрә республикага аларны ышанып тапшыралар. Федераль казначалык башлыгы Роман Артюхин исә киңәшмәнең Казанда уздырылуын Татарстанга карата дәгъвалары булмау белән аңлатты. «Сездә борчылырлык сәбәп юк, шуңа күрә бирегә җыелдык», – диде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

СУЫКТА НИЧЕК ҖЫЛЫНАСЫЗ?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Халык кәефе

Урамда кинәт кенә салкынайтты. Озаграк йөрсәң, суык битләрне чеметә, борынны кызарта. Тик алай зәһәр дип әйтеп булмый әле үзен. Шулай да кеше өстенә җылырак киенергә тырыша. Авылда гына түгел, шәһәрдә дә мамык шәл ябынучы, итек киючеләр күренгәли. Ә сез суыкта ничек җылынасыз?

Фәргать ҺАДИЕВ, Арча урманчылыгының Балтач бүлеге баш урманчысы:

– Салкын дип урманга бармыйча торып булмый. Бер бригада урман кисәргә кереп китте әле. Беренчедән, будкалары бар, икенче яктан, эшләп торгач туңмыйсың. Шунда кереп җылыналар, ашыйлар. Термоста – кайнар чәй. Урманда барыбер ышыграк. Кирәк икән, учагын да ягарга мөмкин. Безнең өстә – салкын үткәрми торган кием. Иң мөһиме – ватылып калмаска. Транспортның ватыла икән, җәяү кайтырга кирәк. Адәм баласы түзә, урмандагы хайваннарга кыен. Пошилар суыкны бик авыр кичерә, шуңа күрә юлларга чыгалар. Алар азык эзли. Урман тавыклары карда йоклый. Җебетеп катырган чакта, чыга алмыйча калалар. Шулай итеп, күбесе кырыла.

Вәзирә ГЫЙЛЬМУЛЛИНА, Минзәлә районы Куян авылында шәфкать туташы:

– Кеше торганын һәм тормаганын исәпләп, авылда барлыгы 22ләп йорт бар. Өйләргә газ кертелгән, бары икесендә генә утын ягып җылыталар. Бүген Рамил яшәгән йортның морҗасыннан төтен чыга иде әле. Үзе бер манзара дип карап тордым. Бүген бигрәк суык – 33 градус. Әле ияләшеп бетеп булмый шул. Атна буе шулай торса, ничек түзәрбез? Аякка итекләрне кидек. Бүген эш буенча районга барып кайттым. Иремә җылы киез итекләр алдык.

Алинә ХӘЙРУЛЛИНА, Питрәч районы Шәле авылы:

– 24 ел сыер сауган идем, өч ай инде эштән туктап тордым. Арыдым, ял итәргә булдым әле. Абзарда мал-туар күп. Туңмыйбыз, өйдә җылы бит. Әле менә мунчага утын ташыйм. Суы катмасын дип, көнаралаш ягабыз. Мунчада парланып, тагын да җылынып китәсең. Бик салкында төнгә каршы мичкә дә ягабыз. Җылы сөяк сындырмый.

Мокатдис ВӘЛИЕВ, Актаныш районы Яңа Кормаш авылы:

– Авылларда берара мичләрне сүтү модага керде бит. Әмма карчыгым Фина безнекен сүттермәде. Мичкә яккан көнне аеруча рәхәт, өйгә җылы бөркелә. Атнага бер мәртәбә ипи пешерәбез. Ул икмәкнең тәмен берни белән дә чагыштырып булмый. Утын табу проблема түгел хәзер. Урманда ауган агачлар күп. Өч кәҗәбез, тавыкларыбыз бар. Без үзебез җылыда утырабыз. Суыкта алар кызганыч. Тиз генә карап керәбез дә башка чыкмыйбыз. Хәзер урамында да кеше юк бит. Өйдә дә, күңелдә дә җылы булсын.

МАТУР БУЛСЫН, ЯКТЫ БУЛСЫН!

Татарстан – мәктәпләрне капиталь төзекләндерү буенча иң алдынгы төбәкләр арасында. Бу хакта «Бердәм Россия» партиясенең Генераль советы Секретаре Андрей Турчак әйтте. Партия уздырган киңәшмәдә программаны тормышка ашыру турында сөйләштеләр.

Андрей Турчак билгеләп үткәнчә, хәзергә вакытта илдә 1384 мәктәптә капиталь ремонт тәгәлләнгән. Ел азагына 1765 мәктәпне файдалануга тапшыру күздә тотыла. Шуның 1535ендә капиталь төзекләндерү эшләре – федераль бюджет акчасына, 230ында – төбәкләр акчасына гына башкарыла. Төбәкләрнең яртысыннан артыгы «Бердәм Россия» Мәгърифәт министрлыгы белән берлектә тормышка ашыра торган программаны 90 процентка яки тулысынча үтәгән инде. Алар арасында Татарстан да бар.

Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия»нең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, республикада мәгариф оешмаларын капиталь төзекләндерүгә зур игътибар бирелә, ә партиянең төбәк бүлеге программаны тормышка ашыру мәсьәләсен даими контрольдә тота.

Татарстанда «Яңа мәктәп» партия проекты иҗтимагый советы рәисе, мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закирова әйтүенчә, республикада 2022 елдан бирле капиталь төзекләндерү программасы кысасында 98 мәктәп ремонтланган. Быел бу максатка 4 миллиард сум тотылган, 31 бина төзекләндерелгән.

Тынычлык һәм татулык символы

10 декабрьдә Халыкара Кеше хокуклары көне билгеләп үтелә. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил **Сәрия Сабурская** шул уңайдан газета аша республика халкын котлый.

«Бүген безнең илдә дәүләт хокук яклау институты актив үсеш ала, законнар камилләштерелә, кеше һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре гарантияләре арта. Шул ук вакытта без кеше хокукларын яклау тагын да зуррак әһәмияткә ия булган авыр вакытта яшибез. Быел, узган елдагы кебек үк, безнең алда торган күп кенә бурычлар «беренче дәрәҗә» статусына ия булды. Аларның берсе – әлбәттә, Ватаннан читтә катлаулы хәлләрдә булган илебез хәрбиләре һәм гражданнары хокукларын яклау», – диелә котлауда.

Сәрия Сабурская әйтүенчә, бүгенге вазгыятьтә кеше хокукларын яклауга, шәхеснең хокукый культурасын тәрбияләүгә зур игътибар бирү аеруча мөһим. «Бу эштә дәүләт һәм бөтен гражданлык җәмгыяте тырышлыкларын берләштерү кирәк. Без Татарстан Республикасында эшебезне нәкъ менә шулай оештырырга омтылабыз, – диде ул. – Халыкара Кеше хокуклары көне безнең җәмгыятьтә һәрвакыт тынычлык һәм татулык символы булсын. Барыгызга да күңел көрлеге, сәламәтлек, иминлек һәм иртәгәсе көнгә ышаныч телим!»

Язучы сүзе

Кеше хокуклары көне

Без бик үк белеп бетермәгән бәйрәмнәр дә бар икән. Халыкара Кеше хокуклары көне, мәсәлән. Дөньяда яшәгән бөтен халык һәм һәр кеше өчен иң мөһим бәйрәм бит инде бу. Кеше хокукы – иң кирәкле нәрсә, җәмгыятьнең, тормышның нигезе, дисәң дә була. Хокукың юк икән, син бик үк кеше була алмыйсың. Кол. Адәм типкесендә йөрүче.

Бәндә тормышы гади генә ул, бер карасаң. Ризыгың бар икән – ашыйсың, булмаса – ашый алмыйсың. Аягың бар икән – йөрисең, булмаса – йөри алмыйсың... Шул рәвешле, ризык та, аяк-кул да, башкасы да мөһим. Әмма иң кирәге – хокук. Чөнки хокукың юк икән, син булган ризыгыңны да ашый алмыйсың, аягыңда да йөри алмыйсың. Ә хокукың бар икән, бөтенләй башка мәсьәлә: нәрсәң бар – шуны ашыйсың, кайда телисең – шунда атлыйсың... Кешене кеше иткән иң төп нәрсә – хокук. Шулай булгач, бу бәйрәм дә иң үзәктә булырга тиештер кебек. Тик алай килеп чыкмаган. Белмим, бу кешенең үз хокукларын бик санга сукмавыннанмы, әллә хокукның кешене санламавыннанмы. Беркем дә белмидер инде аны.

Бер карасаң, кеше хокукы ул – аз гына буталчыграк нәрсә инде. Менә аның сүз иркенә хокукы бар, ни теләсә – шуны әйтергә хаклы, димәк. Тик әйтеп буламы соң? Була, әлбәттә! Әчеңнән генә. Кычкырып әйтергә дә була. Тик күп очракта үткәнеңне, бүгенгеңне, иртәгәңне, үзеңне һәм якыннарыңны, башыңны һәм башка җирләреңне уйлыйсың да бу хокукыңнан файдаланып тормаска буласың. Дәшми каласың. Ә дәшми калырга хакы бармы кешенең? Декларациядә монысы турында берни дә әйтелмәгән.

Яки шәхси тормышка хокук. Интернет, компьютерлар, мобильниклар барлыкка килгәннән соң, бу хакта сөйләү үзе үк мәгънәсезлек булып тоела. Интернетка кереп, нәрсә генә эзләсәң дә, нинди видеофото текстларны ачып карасаң да, синең эзең кала. Шуның буенча эзләгечләр сиңа үзең теләгән мәгълүматны табып бирә. Реклама осталары сине кызыксындырган нәрсәләрне күрсәтә. Әгәр син интернетта кышкы итек эзләгәнсең икән, шундый һәм охшаш итекләрнең рекламасын сиңа күрсәтәләр. Шул рәвешле, интернет синең исем-атыңны, яшеңне, кайда яшәвеңне, нинди әйберләр белән кызыксынуыңны, матди хәлеңне – бөтен нәрсәңне дә белеп тора. Юрган астына качып, хәләл җефетеңнең кулын тотып ятсаң гына монннан вакытлыча котылып торырга мөмкин. Тик хәзерге кеше юрган астында да телефон тотып ята...

Әгәр хатыныңны балыкка киттем дип алдап, сөяркәң янына чабасың икән, телефоның буенча, синең кайсы адреста нинди балык тотып ятканыңны шундук эзләп табалар. Кемгәдер акча күчерсәң яки берәр сүз язып җибәрсәң дә... Бөтен нәрсәңнең дә эзе кала. Кешенең шәхси тормышка хокукы бар, әлбәттә, әмма шәхси тормышы юк.

И, бер карасаң, адәм баласының юк нәрсәләре күп инде ул. Аның каравы әнә шул юк нәрсәләргә аның хокукы бар. Гаделлеккә, закон алдында бердәй җаваплылыкка, туган телендә укуга, төрле җиргә күчүнең мөмкинлегенә, тагын әллә нәрсәләргә.

Боларны уйласам, автомобиль йөртергә хокукы булып та, машинасы булмаган кеше күз алдына килә. Йөртә алмый бит инде ул. Машинасы булып, хокукы булмаса да шулай, җәяүләргә мәҗбүр була. Яки башкаларга утырып йөрергә. Автобуска, мәсәлән. Кайчагында мин «халык» дигәнне дә зур бер автобус сыманрак итеп күзаллыйм. Бу автобуска яки хокукы, яки шәхси машинасы, яки бензинлык акчасы булмаганнар тулган. Барысы да җитеш кешеләр – үз машиналарында. Кайда тели – шунда бара алар, кайчан тели – шунда туктый. Ирекле, тулы хокуклы кешеләр. Андыйлар да җитәрлек бит инде.

Кеше хокуклары көнен мин үзем хөрмәт итәм. Хокукларның көне булырга тиеш. Аларны без санга сугабыз, мөһимгә исәплибез дигән сүз бу. Әгәр шулай икән, димәк, якын гасырларда, бәлки, хокуклы кешеләр дә күбәер, аларның да бәйрәм көне булыр.

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

«Әнә фашист килә!»

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Соңгы вакытларда телевизордан Бөек Ватан сугышы турында фильмнарны күп күрсәтә башладылар. Өйдә миңа: «Нигә һаман иске фильмнар карап утырасың?» – диләр. Мин: «Безнең заманда чыккан фильмнарны карап, үземдә патриотизм хисләре тәрбиялим», – дигән булам.

Әнә «Широка страна моя родная» дигән җыр яңгырый. Сугыш вакытында ук чыккан микәнни ул? Интернетка күз салам, ул 1936 нчы елны ук язылган икән, авторлары – Василий Лебедев-Кумач һәм Исаак Дунаевский. Аны без дә җырлап үстек, иксез-чиксез илем, урманнар, елгалар, басу-кырлар күз алдына килә иде аны җырлаганда. «Молодым везде у нас дорога, а старикам везде у нас почет...» – дип җырлаганда безгә, ягъни яшьләргә юллар ачык, ә картларга хөрмәт хисләренең зур икәнен бала күңелем белән тоеп, шатланып бетә алмый идек. Ничек дөрес тәрбияләгәннәр безне, валлаһи! Җырлар аша күңелебезгә яхшылык, игелек, мәрхәмәт орлыклары сала белгәннәр.

Без мәктәптә театр да уйный идек әле. Режиссерыбыз китапханәче Мәдния апа иде. Шунысы да бик истә калган: тискәре рольләрдә уйнау өчен кеше таба алмый алҗый иде ул. Беребезнең дә, мәсәлән, карак, ак гвардияче яисә немец булып уйныйсы килми генә бит! Чөнки бездә аларга карата чиксез нәфрәт тәрбияләделәр. Беребезнең дә үз өстенә яман ат аласы килмәде. Тик ниндидер бер спектакльдә мине немец офицеры булып уйнарга күндерделәр. Әти-әни дә: «Улым, театр гына бит ул», – диде. Аның нинди спектакль икәнен хәтерләмим инде. Бәлки, спектакльдән бер өзек кенә булгандыр. Ну, фашист образына керер өчен бик тырыштым. Кемнәндер иске китель алып, аңа катыргыдан погоннар ясап куйдым. Укучы фуражкасының кокардасын да үзгәрттем. Аякка әтинең фронттан киеп кайткан яловый итеген кидем. Ул, әлбәттә, бик зур иде, шуңа күрә эчендә аяк шалтырамасын өчен, башына чүпрәкләр тыктым. Мондый киемнәр белән кыяфәтем бик килбәтсез иде, әмма Мәдния апа да, башка укучылар да: «Фашистка ярамаган тагын», – дииделәр.

Спектакль мәктәп сәхнәсендә (залның бер өлеше) уңышлы гына узды. Тик менә Риман абыегызга: «Әнә фашист килә!» – дип төртеп күрсәтә башладылар. Ул чакта ничек гарьләнүемне үзем генә беләм. Яман кушаматтан котылу өчен сабакташларымның ипи шүрлегенә менеп төшәргә дә күп сорамый идем.

Без әнә шулай тәрбияләндек. Бүген беркемне дә мактыйсы, яманлыйсы да килми. Чөнки һәр буын – үз заманы идеологиясе җимеше. Ә идеологияне заман да, бабаң да тудыра.

Бүген яшь буында патриотизм хисләре һәм югары әхлак тәрбияләү яңадан көн үзәгендәге мәсьәләләрнең берсенә әйләнде, ул илебезнең иминлегенә, аның киләчәгенә бәйле. Ватанпәрвәрләр тәрбияләү буенча моннан ике ел элек ил җитәкчесенең фәрманы да чыкты. Әйтүләренчә, яңа буын тәрбияләү өчен чирек гасыр чамасы вакыт кирәк, ә халыкара хәлләр бер дә тотрыклы түгел. Ватан сакчылары тәрбияләргә соңга калдык, диясе килми. Туган нигезне, туган җирне, туган илне ярату хисләре һәркемнең күңелендә бар әле ул дип уйлыйм. Ул хисләрне бары тик кузгаткалап торырга гына кирәк. Бүген дә фашистларга төртеп күрсәтер вакытлар җитте, кемнең кем икәнен бар халык белеп торсын, диюем.

САТАРГА ЯРАМЫЙ, ВАТАРГА?!

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Дөнья һәм Россия икътисадында барган хәлләр, йомшак кына итеп әйткәндә, гаҗәпләнү тудыра. Әйтик, Кытайда инде төзелгән һәм кереп утырып яши башларлык 3 миллиард квадрат метр торакны җимереп ташладылар. Бу торак ил статистикасына үсеш булып кергән иде. Димәк, Кытай икътисадының үсеше кәгазьдә генә. Җитештерелгән, әмма сатылмаган һәм бер тапкыр да кулланылмаган әйберне эчке тулай продуктның үсешенә кертергә ярыймы икән? Статистикага кертсәң дә, кертмәсәң дә, бу квадрат метрлар тормышның матди дәрәҗәсен аз гына да яхшыртмый. Киресенчә, түбәнәйтә, чөнки аларны төзү өчен күпме көч түгелгән, күпме акча һәм ресурслар тотылган. Гамәлләре аек акылга сыймаса да, кытайларга бик аптырарга ярамый. Алар үткән гасырда ук үзләрендәге чыпчыкларны үтереп бетерделәр дә, соңыннан авыл хуҗалыгы шуның нәтиҗәсендә катастрофа хәленә килгәч, чыркылдык кошларны чит илдән сатып алырга мәҗбүр булдылар.

«Йортларны ник җимерәләр соң?» дигән сорауга тукталыйк. Фатирлар сатылмый, шуңа беттән тун ягып котылган төсле кыланалар. Сорауның икенчесе үзеннән-үзе туа: ник сатылмый? Базар икътисады шулай корылган: нәрсә җитешми, шуңа бәя күтәрелә, нәрсә артык, шуңа бәя төшә. Сатылмаса, йортны җимермисең, бәясен төшерәсең. Бәя нык төшсә, алучылар табылмый калмаячак. Менә Россиядә йомырка катастрофасы бара бит әле. ФАС (Монополиягә каршы федераль хезмәт) күпме генә тырышмасын, йомыркага бәя күтәрелүдән туктамый. Бу юллар язылган вакытта Ташкичү кибетендә йомырканың дистәсе – 130 сум. Рәсми хакимиятләр бар көчләренә йомырка бәясе белән тиңсез көрәш алып бара, ләкин нәтиҗәсез. Аек акылның тагын бер мантыйгы эшләми: бәя күтәрелү җитештерүнең артуына китерәчәк һәм озак та тормый артык җитештерү кризисы нәтиҗәсендә бәя төшәчәк һәм тигезләнәчәк. Әмма классик капитализмның гасырлар буе эшләгән бу формуласы хәзер эшләми. Бер Россия һәм Кытайда гына түгел, бар дөньяда икътисадның асты өскә әйләнеп, баштүбән тора.

Сорауның иң кызыклы җиренә килеп җиттек: ни өчен йомырка бәясен төшерергә азапланалар, ә торак йорт бәясе төшүдән куркалар. Россиядә дә 70 миллион квадрат метрлык торак сатылмый ята. Бездә, шөкер, җимермиләр, әмма берәү дә бәяне төшерми. Киресенчә, фатир хакы үсә. Торак бәясе төшү хәзерге глобаль капитализмда катастрофа булып санала. 2008 елгы кризис ничек башланды әле? Американнар торакка чамасыз күп кредит өләшкән дә, халык бурычын түли алмагач, бөтен базар җимерелеп төште: төзелеш компанияләре дә, банклар да бөлде.

Шушы урында Россия Үзәк банкының гамәлләре беразаңлашыла башлый: процент ставкасын күтәреп, Эльвира Нәбиуллина ипотека кредитын авызлыкламакчы була. Әмма кешеләр барыбер ипотека алырга ашкына. Бердән, өстенлекле кредит ставкасы үзгәрми, икенчедән, бүген алмасаң, иртәгә кыйммәткәрәккә алырга туры киләчәк. Соңгы бер-ике елда гына торак бәяләре фантастик темплар белән үсте. Моннан өчдүрт ел элек ипотека алып калучылар сөенә, чөнки оттылар. Гади кеше мондый бәйрәм мәңге дәвам итәр дип уйлый. Бүген алып калсаң, ике елдан соң пүчтәк бәягә алганмын дип шатланырсың дигән мантыйк буенча эш йөртә. Сатылмый яткан торакның бәясен төшереп сатсаң, бу мантыйк җимереләчәк. Кешеләр ипотекага борылып та карамаячак, чөнки иртәгә арзангараккка алып булган нәрсәне ник бүген процент түләп кыйммәткәрәк алырга ди әле. Андый юләрләр күп түгел. Төшенә торгансыздыр: риба капитализмының нигезе җимереләчәк, банклар бөләчәк, фонд базары мәтәлчек атачак. 2008 елгыдан да начаррак булачак.

Алай булгач, ник ипотеканы чикләргә омтылалар соң дигән чираттагы сорауга җавап таләп ителә. Кешеләргә акча өләшсәң, бәя артуы дәвам итәчәк бит инде. Үзәк банк исә алай эшләми: киресенчә, беренчел взносны күтәрә, халык күпләп ипотека алмасын, ди. Торак бәясенең 30 процентын түли алучыларга гына ипотека бирергә җыеналар. Шулай эшләсәң, бары тик түләргә мөмкинлеге булганнар гына кредит алачак дип фикер йөртәләр. Өстенлекле ипотеканы бөтенләй туктатырга ярамый, туктатсаң, төзелеш тармагы гына түгел, бар икътисад җимереләчәк. Кешеләр дә юләр түгел, алар карыйлар: депозитка 16–17 процентка кадәр түләүче банклар бар, ә өстенлекле ипотекага 3–4 процент кына түлисе. Депозитка акча салып, өстенлекле ипотека алсаң, бер миллион сумга йөз меңнән алып 140 мең сумга кадәр отасың. Халык булган акчасын депозитка сала да өстенлекле кредитка фатир ала. Банклар ни өчен өстенлекле ипотека өләшә? Чөнки программаны хөкүмәт субсидияли. Банкир берни дә югалтмый, югалтуны казна каплый. Казна төпсез түгел, ипотеканы чикләүнең тагын бер сәбәбе шунда. Программаны дәвам итсәң, куык барлыкка килә һәм ул шартлый, туктатсаң, инде барлыкка килгән куык бүген үк шартлый. 70 миллион квадрат метр сатылмаган торак – шул куык инде ул.

Йомырка бәясе белән торак бәясе менә шушы урында кисешәләр. Бар инвестицияләр бер тармакка гына салынып, бар бюджет шул тармакка юнәлтелгәч, башка тармаклар нишли? Алар үсүдән туктый һәм бәя күтәрәләр. Күтәрмәсәләр, бөләләр. Бөтен чиновниклар берләшеп, йомырка бәясенә каршы көрәшсә дә, ул төшми. Төп ставканы күтәреп, инфляция туктамаган шикелле инде. Бу хакта без печәнне арбаның бер генә ягына өйгәндә, әйләнеп каплану котылгысыз булуын аңлатып бер генә язмадык. Кырыс контрольгә алып, девальвацияне дә туктата алмадылар: бу юллар язылганда доллар 93 сумга кадәр җитте. Икътисадның үз объектив законнары бар, шул законнар кысасыннан чыктыңмы, җимерелү котылгысыз. Торак йортларны сатасы урынга ватарга туры килә. Ватасың да яңаны төзисең, вакыты җиткәч, яңадан ватасың.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Зөһрә
САДЫЙКОВА

СЫЙЛЫ ЧОР

«ВТ» архивыннан

Кар төшеп, җирләр туңдырып җибәргәч, авыл халкы өчен мәшәкатьле дә, күңелле дә, бәрәкәтле дә чор башлана. Кош-кортларны чистартып, урнаштырып бетергәч, алар зур терлек белән эш итәргә тотына. Күпме көч куеп үстергән мал-туарны урнаштыру авыл халкы өчен зур эш булып тора. Хәер, инде соңгы елларда «сугым чоры» дип кистереп әйтү кимесә дә, күпчелек кеше үзләренә ашарга дигән терлекне кышка аяк атлагач эшкәртә. Алар малларын ничек симертә? Бүген ит бәясе ничә сумнан йөри? Без шул хакта белештек.

Ит кадере

Чүпрәле районының Иске Кәкерле авылы халкы да бу көннәрдә сугым мәшәкате белән яши.

– «Сугым чоры» дип шартлы рәвештә генә әйтәбез инде хәзер, чөнки һәр кешедә диярлек зур суыткычлар бар, алар, мал өлгерүгә карап, эшкәртеп тә куя. Шулай да күпчелек үзләренә дигәнне менә шушы чорга калдыра. Бездә әле, халык, элеккечә, туган-тумача, дус-ишен ярдәмгә чакыра. Ләкин замана рухы да сизелә башлады. Чувашиянең Шыгырдан авылы якын булгач, малларны аннан ике егет килеп эшкәртә. Тана, үгез, сыерны эшкәрткән өчен – 2500 сум, атка 3500 сум алалар, – ди Рөстәм Фәрхуллин.

Аның сүзләренчә, авыл халкының хезмәтен бәяләүчеләр дә, алар тәкъдим иткәнне яратып алып бетерүчеләр дә күп. Шуңа күрә ит сату белән авырлык юк.

– Без үзебез дә маллар суеп сатабыз. Казаннан да, Ульяновскидан да алып китәләр. Авыл ите яхшы була, дип чират торып алып бетерәләр. Ә күп булу сәбәпле, урнаштырып бетерә алмаучылар арадашчыларга да биреп җибәрә. Ләкин алар эшкәртмичә, тере малны ала. Билгеле, бәясе дә арзанрак була, – диде Рөстәм Фәрхуллин.

Ә менә Әлмәт районының Бишмунча авылында быел итне урнаштыру авырлык белән бара икән.

– Хәзер кеше итне азрак ашый башлады шикелле, чөнки бар халыкның да ул бәядән сатып алырга мөмкинлеге юк, – ди шушы авылда яшәүче Айдар Габдрахманов. – Ләкин түбән хакка сатып булмый, чөнки чыгымы да күп. Иң зур чыгым терлек азыгын әзерләүгә тотыла. Мал көр, матур булсын өчен, кабак та бирәбез, бәрәңге дә пешереп ашатабыз. Пешкән бөртек, фураж биреп симертәбез. Шулай тырышып үстергән малыңны сата алмыйча тору гына кәефне бераз кыра, әлбәттә. Башка елларда мондый хәл юк иде.

«Ноябрь, декабрьдә өйгә кайтып кергәнебез юк», – ди Балтач, Арча, Кукмара районнарында яшәүчеләрнең терлекләрен эшкәртүче Илһам Галиев.

– Кеше бик күп, көн саен 3–4 хуҗалыкта эшлибез. Бер малны эшкәртү 2500 сум тора. Малны чалганда иң беренче шарт – аны кыйблага каратып, өч тапкыр «Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим» дип бугазлау. Моннан тыш, чалгач, канның чыгып бетүе мөһим. Шул очракта терлекнең ите тәмле була. Шулай ук пычакның үткен булуы да кирәк, – диде ул.

Кайвакыт ит каты булырга мөмкин. Моның сәбәбен сугымчы, малның карт булуында, диде. Шулай ук ашатуга да бәйле булуын әйтте. Әйтик, ризыкны пешереп ашаткан терлек ите йомшаграк була.

Киңәш

ИТНЕ САТЫП АЛГАНДА, НӘРСӘГӘ ИГЪТИБАР ИТӘРГӘ?

– Кызгылт, бераз гына алсу төстәге ит – иң яхшысы. Аның мае да булырга тиеш. Ит арасында май җепселләре күренеп торганны курыкмыйча сатып алырга мөмкин. Ә артык куе кызыл һәм зәңгәрсу булып торган ит күңелдә шик уятырга тиеш. Башкорт токымлы үгезләрнең ите иң яхшысы санала. Алар – ит өчен бик яхшы токым. 1 елда 3,5 центнер ит бирә. Ләкин алар арасында холыксызраклары күбрәк очрый.

– Малны суйгач та, итен шунда ук пешерергә киңәш ителми. Ит бер тәүлек тирәсе салкын урында торырга тиеш. Яңа суелган итнең мускуллары тартышып тора. Шуңа да аны ашка салгач, шулпага ят тәм чыгарга мөмкин.

Кайда ничек?

Яшел Үзән районы:
алгы бот – **440 сум**,
арт саны **450–480 сум**,
Биектау районы: **450 сум**,
Кукмара районы: алгы бот – **420–430**,
арткысы – **450 сум**,
Азнакай районы: **450–480 сум**,
Мөслим районы: **470–480 сум**,
Әлмәт районы: **480–490 сум**,
Балтач районы: тана итенең арт саны – **420 сум**, алгысы – **380 сум**,
үгез итенең арт саны – **430–450 сум**,
ал саны – **420 сум**,
Чүпрәле районы: **450 сум**,
Алабуга районы: **480–500 сум**,
Киров өлкәсе: **450–460 сум**,
Башкортстан Республикасы: **450–480 сум**.

«Терлек сыйфатлы ризык ашап үсәргә тиеш»

Балтач районының Алан авылында яшәүче Хәлим Кәримовның белмәгән эше юк. Ул – оста сугымчы да, аучы да, умартачы да, гомумән, кызыксынучан һәм авыл тормышын төптән белүче кеше.

– Заманында үзем дә сугымга күп йөрдем, тик хәзер үзебезнең якыннарга гына булышам. Чөнки һаман кан агызуны нервыга бәрә торган эш дип саныйм. Соңгы вакытта сугымчылар арасында терлекнең муен тамырына яки маңгаена әйбер кадап үтерү гадәте барлыкка килде. Болай эшләү ярамый. Ит хәләл булсын өчен, терлекне кыйблага каратып, «Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим» дип чалу гына җитми. Аны госелле, намаз укучы кеше чалса, күркәмрәк. Шуңа күрә хәләл итеп чалуга тиешле игътибар бирергә кирәк, дип уйлыйм.

– Хәлим абый, терлек ничә яшьтә чалырлык булып өлгерә?

– Үгез малы 1,5 яшьтә чалырлык була. Шуннан соң аның ите тыгызлана, катылана. Тананың 2 яшен тутырып чалырга кирәк, чөнки гәүдәсе кечкенәрәк була. Ләкин аннан да озаграк тотарга киңәш ителми, чөнки ул тазарып китә. Артык тазарып китеп, итен май каплап алса да яхшы түгел. Әмма майсыз итнең дә тәме булмый.

– Итнең кайсы өлеше тәмлерәк?

– Үпкә-бавыр белән эчәкне бүлеп тора торган өлеш – итнең иң тәмле җире. Ул 10–15 минутта пешә. Аннан кала билдәмә (вырезка) – шәп җире. Ботлап алганда, малның ал ягы әйбәтрәк. Кеше арт санына кызыга, ләкин алгы өлеше тәмлерәк тә, йомшаграк та. Алгы як кабыргалы була. Юка кабырга шулпада бик тәмле булып, кабарып пешә. Арткы ягы – фаршка, алгысы шулпага кызы. Сөяк янындагы ит тәмле була. Үгез ите бик майлы түгел, тыгыз була, ите күп чыга.

– Ашарга дигән малны ничек симертәсез?

– Чаласы малның төп ризыгы башак булырга тиеш. Бөртекнең үзен генә дә, бәрәңге белән дә пешереп ашатсаң яхшы. Урман печәне витаминнарга бай булса да, ул малны ныгытмый, аның өчен люцерна кирәк. Моннан тыш, көтүдә йөргән малның ите тәмле була, чөнки ул, беренчедән, үзенә кирәген үзе эзләп ашый, икенчедән, хәрәкәтләнгән малның ите йомшаграк була. Бездә хәзер шәхси хуҗалыкларда да терлекләргә гранула ашата башладылар. Менә анысын хупламыйм. Әйе, мал күзгә күренеп күтәрелә, көрәя, матур булып үсә. Тик аның ите дә тәмле булмый, ят исе дә килә. Ә табигый шартларда хайванны тиз үстереп булмый, чөнки һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Чеби мисалында гына карыйк: кош фабрикаларында бройлер 40 көндә өлгерә, ә шәхси хуҗалыкта аны озаграк үстерергә кирәк. Бозауга да, тизрәк үссен өчен, витамин белән укол кадыйлар. Коры сөтнең дә төрлесе бар. Аны да ясалма үстерү өчен кулланалар. Мин һәр нәрсә табигый шартларда үсәргә, өлгерергә тиеш дигән фикердә.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ГАЗ КУЫГЫ

Газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү турындагы килешүне киләсе елда да төзеп булачак.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Йөрәккә шом керде»

– 40 мең түгел, 4 мең сум да артык акчам юк. Шуңа күрә мин яши торган күпкатлы йортның «Ватсап» төркемендә яңалык турында ишетүгә, газ оешмасына юл тоттым. Эш көне булуга карамастан, коридор тулы халык җыелган иде. Белгечкә әләгә алмадым, кимендә ике-өч сәгать чират көтәргә кирәк, диделәр. Юньләп аңлатучы да булмады. Оешма хезмәткәрләре, халык бераз кимегәч, үзләре хәбәр салырга вәгъдә бирде инде, нишләргә дә белгән юк. Яңа елга кадәр килешү төзергә кирәк булгач, бу хакта алданрак хәбәр итәргә ярамады микәнни? – дип, редакциягә шалтыратты Казанда яшәүче Наилә Сафиуллина.

Башкаладагы хәлләр район халкын да аякка бастырган. Кукмарада үз йортлары белән яшәүче Гөлназ һәм Ленар Вафиннар, чакыручы булмаса да, газ оешмасына барып, килешү яңартып кайткан.

– Районда бу хакта ләм-мим бер сүз дә әйтүче юк. Интернеттан гына белдек. Килешүне вакытында төземәсәң, газны да өзәргә мөмкиннәр ди бит. Газчыларга шалтыраткан идем, ыгы-зыгы куптармагыз дип тынычландырырга ук тотындылар. Йөрәккә тагын да шом керде. Икенче көнне кирәкле документларны тутырып кайттык. Район бүлекчәсендә чиратлар юк, безгә кадәр өч-дүрт кенә кеше бар иде. Барысы да таныш-белешләрдән ишетеп, газ килешүен яңартырга килгән, – дип сөйләде Гөлназ Вафина.

Бер көндә – 300 кеше

Эш шунда ки, быел 1 сентябрьдән ил күләмендә «Газ белән тәэмин итү турында»гы федераль законга һәм РФ Торак кодексына төзәтмәләр үз көченә керде. Аның нигезендә, газ челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү, шул исәптән, фатир һәм йортлардагы газ плиталәрен, казаннарны һәм газ мичләрен ремонтлау белән чимал җибәрүче оешма гына шөгыльләнә ала. Моңа кадәр идарәче компанияләр яки милек хуҗалары бу эшкә шәхси оешмаларны да җәлеп итә алды. Рәсми мәгълүматларга караганда, республикада шундый 200гә якын (!) компания бар. Озын сүзнең кыскасы, алга таба Татарстанда газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү белән «Газпром трансгаз Казан» гына шөгыльләнәчәк. Тик моның өчен оешма белән килешү төзергә яки булганын яңартырга кирәк. Әнә шуның аркасында шау-шу килеп чыкты да инде.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтик: закон кабул ителгәч тә, газчылар халыкка газ килешүләре турында хәбәр итәргә ашыкмады. Ә ноябрь азагында телевидение тапшыруларының берсендә «Газпром трансгаз Казан» вәкиле штрафлар турында искә төшергәч һәм бу матбугат чараларында яктыртылгач, мәхшәр башланды.

– Без үзебез дә аптырашта, – ди башкаладагы газ бүлекчәләренең берсендә эшләүче Гүзәл Хәйретдинова. – Ел азагында бу кадәр халык килер дип көтмәгән идек. Дөрес, законга төзәтмәләр үз көченә кергәч, газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү турындагы килешүне яңадан төзергә теләк белдерүчеләр берәмсәрәм килә башлаган иде. Аларга барысын да аңлаттык, яңа килешүләр рәсмиләштердек. Бер абунәчегә әлеге төр хезмәтне күрсәтү өчен 10–15 минут вакыт кирәк. Тик бу атнадагы кебек коридор тулы халыкны берничек тә кабул итеп бетерә алмыйбыз. Кичә безнең бүлекчәгә генә 300гә якын кеше килде. Алардан шәхси мәгълүматны эшкәртергә ризалык алып, исем-фамилия һәм адресларын гына теркәп барабыз. Яңа елдан соң үзебез хәбәр итәбез дип, тизрәк озатырга тырышабыз. Чиратларны ничек тә таратырга кирәк. Шалтыраткач, әзер килешүне килеп кенә аласы була, кыскасы. Әмма бу кадәр кешегә ул документны кем һәм кайчан тутырып бетерәчәге билгесез. Ялсыз һәм төнлә эшләсәк кенә. Көндәлек эшләр дә бар бит. Әлегә аңлатучы юк.

Газны өзмиләр

Пошаманга төшкән халыкны сишәмбе көнне Хөкүмәт йортында узган брифингта Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрының беренче урынбасары Алексей Фролов тынычландырды.

– 2024 елның 1 гыйнварына кадәр газ килешүен төзергә өлгермәүчеләр зәңгәр ягулыксыз калмаячак, – диде ул. – Йорттагы газ челтәрләреннән файдалануга бәйле килешүләрне бер оешмага тапшыру турында карар ил күләмендә кабул ителде. Тагын бер кат искәртәм: бу – федераль дәрәҗәдәге эш. 2024 елның 1 гыйнварына кадәр идарәче оешмалар килешүләрне яңартырга тиеш. Ни кызганыч, республиканың кайбер районнарында «Таттрансгаз» инде хәзердән үк милек хуҗалары белән дә яңа килешүләр төзи башлаган. Нәтиҗәдә аңлашылмаучанлык килеп чыккан. Физик затларга яңа елга кадәр яңа документ алу мәҗбүри түгел. Моны алга таба да эшләргә мөмкин. Моңа карап кына беркем дә газсыз калмаячак.

Министрның беренче урынбасары әлеге мәсьәлә тирәсендә туган шау-шуны урынсыз дип тә атады.

– Бернинди ыгы-зыгы булырга тиеш түгел. Мин физик затлар белән килешүләрне яңартуга бәйле бернинди кыенлык та күрмим. Аны ел дәвамында хәл итәчәкбез. «Таттрансгаз»ның кайбер бүлекчәләре, берьюлы ике эшне башкармакчы булып, таякны артык бөгеп ташлаган, шул гына, – диде ул.

Авыл миченеке ярый

«ВТ» хәбәрчесе, аңлатма сорап, «Газпром трансгаз Казан» оешмасының матбугат хезмәтенә дә мөрәҗәгать итте.

Аннан алынган мәгълүматларга караганда, 2023 елның 1 сентябренә кадәр газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү турында килешү төзегән шәхси йорт хуҗаларына, шул исәптән авыл халкына да, кулдагы килешүнең вакыты чыкканчы, яңасын төзергә кирәкми. «Ә менә идарәче компанияләр һәм күпфатирлы йортларда яшәүчеләр, яңа закон нигезендә, 2024 елның 1 гыйнварына кадәр килешү төзергә тиеш», – диделәр матбугат хезмәтендә.

Килешү төзү өчен документларны интернет аша да җибәрергә мөмкин. «Моның өчен кирәкле документларны һәм гаризаның күчермәсен **dogovor@tattg.gazprom.ru** электрон адресына юлларга гына кирәк. Шул рәвешле абунәче «Газпром трансгаз Казан» оешмасына шәхси мәгълүматны эшкәртергә ризалык бирә. Документларны тикшергәннән соң, физик затның электрон адресына килешү әзерләнә башлау турында мәгълүмат җибәрелә. Теге яки бу документ җитмәгән очракта да, бу хакта хәбәр хаты киләчәк. Килешү әзер булгач, аны килеп аласы гына кала. Документ ун эш көнендә бирелә», – дип аңлаттылар.

Фикер

Михаил ФРОЛОВ, «Газпром трансгаз Казан» оешмасы генераль директоры урынбасары:

– Татарстанда 1,6 миллион абунәче физик зат исәпләнә. Аларның 10 процентка якыны яңа килешү төзергә өлгерде инде. Закон кабул ителсә дә, әлеге эшне тиз генә бетереп булмаячагы аңлашыла. Шуңа күрә килешүләр төзүне киләсе ел азагына кадәр дәвам иттерергә җыенабыз. 2024 ел беткәнче штрафлар да булмаячак. Халыкка күпләп хәбәр сала башласак, тагын ыгы-зыгы башланырга мөмкин. Шуңа күрә билгеле бер график буенча гына эшлибез. Газ оешмасына чакырып шалтыратканны көтсәгез, яхшырак. Авылда яшәүчеләргә иң соңыннан хәбәр салачакбыз. Газдан өзү һәм штраф салу ул – килешү төзергә теләмәүчеләргә карата кулланыла торган иң соңгы чара. Ягъни әгәр физик зат шалтыратып чакырганнан соң да газ бүлекчәсенә килми икән, аңа бу хакта язмача хат җибәрелә. Аны да күрмәмешкә салынса, без Татарстан Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итәбез. Алар да, административ эш кузгатканчы, абунәче белән элемтәгә кереп караячак әле. Әнә шуннан соң да файдасы булмаса, штраф кына кала. Физик затларга ул – 1000–2000 сум, юридик затларга исә 40 меңнән 100 мең сумга кадәр тәшкил итә.

КИЛЕШҮНЕ ЯҢАРТУ ӨЧЕН НИНДИ ДОКУМЕНТЛАР КИРӘК?

✓Шәхесне раслаучы документ (паспорт, балигъ булмаган милекчегә туу турында таныклык, ышаныч язуы).

✓Гариза тапшыручының милеккә хокукларын раслаучы документ.

КЫШКЫ МӘШӘКАТЬ

Яңа карның – иске мәшәкате. Ел саен шул ук кыш килсә дә, кар күпләп яугач, югалып, аптырап калабыз. Быелгысы көттереп кенә яуса да, көртен дә, бозлавыгын да, калаларда исә «бөке»ләрен дә күрсәтергә өлгерде инде. Кышын юлларны кем тәртиптә тота? Эшче куллар, көрәк, техника җитәрлекме? Районнарда, авылларда бу мәсьәләне ничек хәл итәләр? «ВТ» шуны ачыклады.

Юмарт кыш

Кайбыч районындагы Кошман авылы җирлеге башлыгы Лилия Сафина сүзләренә караганда, сала урамнарын кардан арындыру эше үзара салым акчасына башкарыла.

– Кардан чистарту эше – тулысынча авыл советы өстендә. Без «Садриева» крестьян-фермерлык хуҗалыгы белән килешү төзибез дә аларның тракторы юлларны чистарта. Бу эш үзара салым акчасына башкарыла. Кыш төрлечә килә бит, кары да төрлечә ява. 2021–2022 елларда, мәсәлән, бу эшкә 189 мең сум акча тотылган иде. Ул елны әле бюджет акчасыннан да өлеш чыгардык, – дип сөйләде ул безгә. – Быел да кыш карлы булырга охшап тора. Быел мәнә 24 ноябрьдә үк юлларны кардан чистартырга чыктык. Кардан чистартучыбыз белән даими элемтәдә торабыз. Алдан һава торышын да күзәтәбез. Гадәттә трактор иртәнге сәгать 4тә чыга. Эшнең бер сәгате – 1500 сум. Кешеләр – эшкә, балалар – мәктәпкә, бакчага барганда юллар тәртиптә булсын, дибез. Төп юлларны гына түгел, тыкрыкларны, мәчет, зират юлларын да тәртиптә тотабыз. Кешеләр дә тәртипкә, чисталыкка ияләшкән. Моны тәэмин итәргә кирәк, димәк. «Кошманның юллары ялт итеп тора!» – дип юкка гына әйтмиләр. Мондый сүзләрне еш ишетәбез. Барысы да чагыштыруда күренә.

Биектау районындагы Алан-Бәксәр авылы җирле үзидарә башлыгы Зөһрә Гарифуллина да, юлларны кардан арындыру эше үзара салым акчасына башкарыла, ди. Җирлеккә берничә авыл керә.

– Өч авылда кышкы юлларны кардан чистарту эшен җирлектә урнашкан авыл хуҗалыгы оешмасы – «Әсән» ширкәте башкара. Тагын ике авылда юлларны җирлектә эшләп килүче эшмәкәрләр чистарта, – диде ул. – Бюджетта кардан чистарту эшенә каралган акча бик аз шул, шуңа күрә дә үзара салым акчасын куллануны бик кулай дип таптык. 2024 елга да эшләнәчәк эш төрләренә керттек.

Кем җаваплы?

Булат ЗАКИРОВ, «ВТ» юристы:

– Россия Хөкүмәтенең 03.04.2013 № 290 карары (16 пункт, 2 өлеш) нигезендә, йорт яны территориясен җыештыру һәм йортның гомуми милке өчен идарә итүче оешма җаваплы (идарәче компания, төзүче компания (застройщик), ТСЖ). Шушы ук карарда елның җылы һәм салкын вакыты өчен мәҗбүри минималь эш күләме расланган. Шулай итеп, салкын көннәрдә коммуналь хезмәткәрләр: люк капкачларын һәм янгын гидрантларын кардан һәм боздан чистарта; ишегалдындагы юлларны, мәйданчыкларны һәм парковкаларны кардан чистарта; кар булмаган территорияне себерә; йорт яны территориясен боздан чистарта; юлларга тозлы ком сибә; түбәдәге бозны (сосулька) бәреп төшерә. Эшләрнең һәр төренә таләпләр Россия Дәүләт төзелешенең 27.09.2003 елгы 170 номерлы карарында теркәлгән. Анда барысы да бар: тротуарларны кайчан себерергә һәм чистартырга, юлларны кардан чистарту ешлыгы, чүп контейнерларының нинди булырга тиешлеге һәм башкасы. Административ биналарның территорияләрен җыештыру өчен бина өчен җаваплы булган җитәкче җавап бирә.

Җирле әһәмияттәге юл	**Авыл советы яллаган подрядчы оешма вәкилләре**
Төбәк әһәмиятендәге юл	**Төбәктәге юл хуҗалыгы эшчеләре**
Федераль юл	**«Росавтодор» дәүләт корпорациясе**

kzn.ru

Татарстан башкаласында юлларны кардан арындыруда 1,1 меңнән артык техника катнаша, 473 мең тоннага якын тоз-ком катнашмасы, 97 мең тонна техник тоз әзерләгәннәр.

– Авылларда урам юлларын бездә үз техникалары белән авыл хуҗалыгы җәмгыяте ача. Колхоз булгач, ул яктан бик җайлы, – ди Саба районы Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгы Булат Мәүлетов. – Эшләрен вакытында башкаралар. Түбән Шытсу өч авылны берләштерә, хәзерге вакытта авылларда хуҗалык саны – 291, шуларда 662 кеше яши. Халык әле кулына көрәк тотып, ишегалларын чистартудан бизмәде. Дөрес, көрәк урынына күпкә кулай булган заманча кораллар да күренгәли.

– Шәһәрдә 15 берәмлек техника эшли. Бик күп итеп кар яуган очракта, эшкә иртәнге 3тә үк тотыналар. Төнге кизү тору да каралган. Гадәттә, бу кичке 9дан иртәнге 7гә кадәр. Ике техника хезмәт күрсәтә. Шунысын да искәртик: идарәче компанияләрнең – үз режимы, үз графигы, – дип аңлаттылар «ВТ»га Буа районы хакимиятендә.

Карлы башкала

«Эшлекле дүшәмбе»ләрнең берсендә Казан мэры Илсур Метшин:

– Кар авыл хуҗалыгы, кырлар, агачлар өчен кирәк, әмма безнең өчен бу һәрвакыт кыенлык тудыра, – дигән иде.

Мэр сүзендә хаклык бар инде. Кар яуса, «бөке»ләр, аварияләр саны арта, җәмәгать транспорты соңарып йөри башлый... Ә кар көртләреннән чистартырга, боз ватарга кеше юк. Сер түгел, кышкы сезон җитәрәк күпчелек урам себерүчеләр эшеннән китә.

Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, Россия буенча урам себерүчеләргә ихтыяҗ 1,5 тапкыр арткан. Шул ук вакытта тәкъдим ителгән хезмәт хакы да 20 процентка үскән һәм 32,4 мең сумны тәшкил иткән. Казанга 500ләп эшче кул җитми. Хезмәт хакы – 22–36 мең сум. Быел башкаладагы «карлы-бозлы көрәш»кә 2700ләп урам себерүче чыга икән.

Башкала урамнарында (Яңа Савин, Совет, Вахитов, Киров районнары. – **Авт.**) күргән кайбер урам себерүчеләргә сүз катып карады «ВТ» хәбәрчесе. Шуннан чыгып аларны нәрсә борчыганын да шәйләп була. Күпчелек, билгеле инде, хезмәт хакының аз, ә башкарасы хезмәтнең шактый авыр булуыннан зарланды. Кар көртен бер урыннан икенче урынга күчерү генә түгел бит әле бу, бозын да ватасы бар. Ә бу хезмәттәгеләрнең күпчелеге – өлкән яшьтәгеләр.

Тагын бер борчыган мәсьәлә – кешеләрнең мөнәсәбәте. «Күпләр безнең эшкә чын мәгънәсендә төкереп кенә карый. «Тиеш» дип кенә кабул итә. Аңлау юк, тупаслык бар. Кемдер ком сипсәң – яхшы, ди, кемдер зарлана», – диде Бауман урамындагы бер урам себерүче.

Мөнәсәбәт димәктән. Чаллыда яшәүчеләрдән үрнәк алырга буладыр. Торак комплексларының берсендә яшәүчеләр, акча җыешып, урам себерүчегә кар чистарткыч бүләк иткәннәр әнә. Валерий Салихов 2017 елдан бирле бер идарәче компаниядә урам себерүче булып эшли икән. Карлы-буранлы көннәр өчен тимер ярдәмче – әлбәттә, бик кирәкле бүләк. «Булганың өчен рәхмәт!» – дигәннәр шул йортта яшәүчеләр, аңа бүләкне тапшырганда. Күңел тулып, еламас җирдән еларсың, Валерий Салихов әйтмешли.

Хезмәтенә күрә – түләве

46 яшьлек әңгәмәдәшебез Русланны без «Авито» аша таптык. Территорияне кардан, боздан чистарту белән беренче генә ел шөгыльләнми. Эшен тиз һәм вакытында башкара. Түләүне сәгатьләп ала. Көрәге дә, бозваткычы да үзенеке. Кирәк икән, түбәгә дә менә ала. Үзе генә дә, иптәшләре белән дә эшли.

– Кешеләр шалтырата, чакыра, ошатсалар, кабат чакыралар, андыйлар да күп. Әлбәттә, физик хезмәт булгач, кулларга да, аркага да рәхәт түгел. Әмма мин эшемне сыйфатлы һәм төгәл башкарырга тиеш, шул уй белән эшлим. Алай иткәч, җиңелрәк. Син эшләгән эштән кеше канәгать калырга тиеш, – дип сөйләде ул. Эш хакын гына сер итеп саклый әңгәмәдәшебез. Хәер, хезмәтенә күрә түләве тиң бугай.

Шәһәр эчендә дә, шәһәрдән читтә урнашкан шәхси йортларга да бара Руслан. Андыйлар еш чакыра икән. Әле менә күптән түгел Көек бистәсендә бер ханымның ишегалдын чистартырга барган. Ире чит илдә икән. Ханымның исә кунаклар кабул итәргә җыенып йөргән мәле. Кунакчыллык ишегалдыннан ук башлана, дигәндәй, йорт тирәсенең чиста булуын теләгән. Ярый менә Руслан ишеләр бар! Шушы көннәрдә чиркәү тирәсен кардан чистартырга барганнар. Эшсез ятмый, кыскасы.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

11 декабрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем…» 12+
12.00, 22.40 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00, 01.05 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «ЖЁЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Путь» 16+
01.30 «Туган җир» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
18.20, 22.15 «ҖИДЕ ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
18.50, 22.40, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25, 00.40 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Туган авылым» 12+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ИЩЕЙКА» 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
02.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обман веществ» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Шоу Аватар» 12+
23.10 «Звезды сошлись» 16+
00.40 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Юбилейный вечер Александра Шоуа 16+
02.10 «АДВОКАТ» 16+

ДОМАШНИЙ
10.05 «СТАРУШКИ В БЕГАХ-2» 16+
19.00 «ВОРОН» 16+
23.00 «Твой Домашний доктор» 16+
23.15 «БЕГИ, НЕ ОГЛЯДЫВАЙСЯ!» 16+
02.50 «Москвички» 16+
06.05 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА
06.30 «КОДОВОЕ НАЗВАНИЕ «ЮЖНЫЙ ГРОМ» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Скрытые угрозы» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» 12+
13.15 «По горячим следам» 16+
13.30, 03.20 «СМЕРШ» 16+
18.00 Главное 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
20.35 «Легендарные матчи» 12+
23.10 «Фетисов» 12+
23.55 «Люди Донбасса» 16+
00.10 «СУМКА ИНКАССАТОРА» 12+
01.45 «ПОЕДИНОК В ТАЙГЕ» 12+
02.55 «Перелом. Хроника Победы» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?
Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 11 декабрь
06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Актуаль әңгәмә»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Гөлчәчәк Галиева. «Газзабану». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 12 декабрь
06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Актуальное интервью»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.10 Прямой эфир
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты
18.25 «Саз» ансамбле язмалары

Чәршәмбе, 13 декабрь
06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Юллар чатында»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.20 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 «Актуальное интервью»
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Время молодых»
18.25 Ришат Төхвәтуллин җырлый

Пәнҗешәмбе, 14 декабрь
06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Перекресток»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Прямой эфир
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «На волне Татарстана»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар»

Җомга, 15 декабрь
06.00 «Иртәнге нур»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты
18.25 Эстрада музыка концерты

Шимбә, 16 декабрь
08.10 Хәйдәр Бигичев иҗатына багышланган әдәби-музыкаль композиция
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре»

Якшәмбе, 17 декабрь
08.10 «Между Волгой и Уралом»
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Фоат Садриев «Кайту». Радиоспектакль

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Сәрия
МИФТАХОВА

ӨМЕТ ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

УКЫТУЧЫЛАР ЕЛЫ ЙОМГАКЛАРЫ

Хисап эше кимесен, хезмәт хакы артсын, әти-әниләр укытырга өйрәтмәсен. Укытучылар һәм остазлар елына педагоглар әнә шундый хыяллар белән аяк баскан иде. Укытучыга карата хөрмәт арттымы? Җылы сүзләрне кызганмыйбызмы? Кесә ягы ничегрәк: педагогларның әфлисун алырга акчасы җитәме? «ВТ» хәбәрчесе мөгаллимнәрнең өметләре ни дәрәҗәдә аклануын белеште.

Әфлисун һәм укытучы бәясе

Казандагы «Адымнар» күптелле мәктәпләр челтәре директоры, Дәүләт Советы депутаты Айдар Шәмсетдинов әйтүенчә, хәзерге вакытта мәктәптә эшләүче укытучыларның барысы да – фидакарь кешеләр.

– Укытучылар елында педагогларга игътибар артты. Әмма кызганыч, хәл итәсе мәсьәләләр шактый күп, – ди Айдар Шәмсетдинов. – Иң беренчесе – укытучылар кытлыгы. Һәр төбәккә хас бу. Икенчесе – хезмәт хакы. Кызыксындыру өчен лаеклы акчаны түләргә кирәк. Хәзерге вакытта түләнә торган эш хакы яшьләрне һөнәргә әллә ни җәлеп итми. Россиядә уртача 60 мең сум хезмәт хакы алу өчен укытучыга ике ставкага эшләргә кирәк. Бу инде аның эмоциональ яктан януына, аруына китерә. Кичке сәгать 6да мәктәптән кайткач, әле өй эшләрен тикшерәсе бар. Өстәвенә сыйныф җитәкчесе дә булса…

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бүген мәктәптә бары фидакарьләр генә эшли.

Җәмгыять тарафыннан бәяләнмәү – гаделсезлек. Укытучы елында укытучыларга түләнә торган төп ставка 1600 сумга артты. Шул ук вакытта ике ел эчендә әфлисун бәясе 4 тапкыр үсте. Менә хәзер үзегез уйлап карагыз: без – укытучыга карата гадел җәмгыятьме?

Мөнәсәбәт

Быел укытучының кәефен ничек кенә күтәрергә тырышмадылар: ел дәвамында концерты да, төрле тамашасы да күп булды. Һәр районда ветеран укытучылар, укытучылар династияләрен искә алдылар.

– Укытучының дәрәҗәсе артты. Мөгаллимнәр сәхнәгә чыкканда, залда утыручылар аягүрә басып сәламли. Бу – дәрәҗә түгелме? Район җитәкчеләре арасында: «Чыгыш ясаганда беркемнән дә оялмыйм һәм курыкмыйм, ә менә укытучылар каршында кул-аяклар калтырый башлый», – диючеләр бар. Бу – хөрмәт билгесе түгелме? – ди Әгерҗе районының мәгариф бүлеге башлыгы Вәсилә Сафиуллина.

Районда 703 укытучы исәпләнсә, шуның 75е – яшьләр. Вәсилә Сафиуллина әйтүенчә, планлаштырылган чараларның берсе дә кәгазьдә калмаган. Балалар арасында укытучыга кагылышлы бәйгеләр уздыру, фильмнар карау дисеңме, мәктәпне элек тәмамлаучылар белән очрашулар үткәрүме…

Сиздегезме?

Ә менә Айсинә Галимова (исеме үзгәртелде. – **Ред.**) Укытучылар һәм остазлар елында бернинди дә үзгәрешләр сизмәгән. Аның әйтүенчә, хезмәт хакы шул ук, эше дә кимемәгән: БДИга әзерләү, PISA, функциональ белемне тикшерүләр, бушка олимпиадага әзерләүләр…

– Өсте-өстенә яңа проектлар чыгаралар. «Сферум» платформасын уйлап таптылар. Анда эш чиктән ашкан. 1 гыйнвардан яңа электрон журнал булачак. Шуның буенча сынау үтәбез. Олы яшьтәгеләргә бик кыен. Көннән-көн укытучыларның өмете сүнә бара. «Эштән китәргә кирәк», – диючеләр дә бар, – диде ул. Айсинәнең ире дә – укытучы. Аларның гаиләсенә теплоходта сәяхәт бүләк иткәннәр.

Түбән Кама районының Кама Аланы бистәсендәге башлангыч сыйныф укытучысы Зөлфирә Кинева Укытучылар һәм остазлар елынан берни дә өмет итмәгән. «Авыл укытучысы» программасында отып, Удмуртиянең Ижау шәһәреннән килгән ул. Свердловск өлкәсенә барырга тиеш булган, әмма Татарстанны сайлаган. Программа буенча алган 1 миллион сумны әле тотмаган. Анысы – киләчәк эше.

– Килүгә арендага торак тәкъдим иттеләр. Кирәклегемне тойдым. Ә бу – иң мөһиме. Бар да яхшы, тик туган як кына бик сагындыра. Айга бер мәртәбә кайтып йөрим. Ике ара – 4,5 сәгатьлек юл. Программа шарты буенча мин биредә биш ел эшләргә тиеш. Әгәр ошаса, төпләнеп тә калырга исәбем бар, – ди 30 яшьлек Зөлфирә. – Мәктәпкә эшкә барганда документ тутырасың да, компьютерда эшләргә кирәклеген дә беләсең. Әгәр бу һөнәрне сайлыйсың икән, авырлыгына да түзәсең.

Сөенер өчен күп кирәкме?

Менделеевск районында укытучыларга арендага бирү өчен 60 фатирлы йорт төзиләр. Тора-бара аны укытучыга калдыру ягын да караячаклар. Район башлыгы Радмир Беляев әйтүенчә, быел «Аммоний» заводы укытучыларга 10 миллион сум акча бүлеп биргән. Бәйгедә катнашып, яшь укытучылар – 150 мең, директорлар 200 мең сум грант откан. Укучысы фән олимпиадасында җиңсә, укытучыга 10–30 мең сум акча бирелә. Белемнәрен күтәрү өчен, 1 миллион сум акча бүленәчәк. «Ел укытучысы» бәйгесен дә оештырырга җыеналар. Бу әле – яңа проект. Иң яхшы фән укытучыларын – 50шәр мең, гран-при иясен 150 мең сум акча көтә.

Минзәлә районының Урыс мәктәбендә 22 балага 11 укытучы белем бирә. Кайбер сыйныфта – 1 генә бала.

– Бала саны аз булгач, укытырга җиңелрәк. Моны укытучыларның үзләренә дә әйтәм. Шөкер, мәктәпне саклыйлар әле. Авылда бакча бетте, мәктәп тә клуб кына бар. Бөтен нәрсәне экономиягә генә корып булмый бит. Аннан соң халык ничек яшәргә тиеш? – ди директор Илдус Мәүҗиев. – Ел дәвамында укытучыга хөрмәт күрсәттеләр. Акча да мөһим. Укытучылар Президентның Май указлары буенча ике тапкыр премия алды. Уртача күләме – 22шәр мең сум. Бу начармыни? Бик сөенештеләр.

Укытучыга нинди ярдәм бар?



> Республикада «Алгарыш», «Безнең яңа укытучы» грантлары тормышка ашырыла. Соңгысын **2011–2019** елларда **1680** педагог откан. Аларга ай саен **10** мең сум акча түләнә.
> Быел педагогик хезмәткәрләргә **36** мең ноутбук сатып алынган.
> «Татарстанның мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы», «Тел, мәдәният, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен» һәм «Яшь мөгаллим» күкрәк билгеләре булдырылды.
> **1** гыйнварыннан яшь укытучыларга өч ел дәвамында **2,5** мең сум өстәмә акча түләү кертелгән.
> Сыйныф җитәкчеләренә федераль бюджеттан **5** мең сум акча түләнә. Республика түләүләре, ягъни айга **550** сум һәм һәр бала өчен **80** сум акча да саклана.
> **2021** елның **1** гыйнварыннан авыл җирлегендә яшәүче укытучыларга җылылык, ут өчен субсидия бирелә.
> Кайбер районнарда укытучыларны эшкә урнаштырганда, җирле бюджеттан бер мәртәбә бирелә торган түләүләр, арендага торак каралган.
> Укытучылар социаль ипотека программасында катнаша ала. Быел республика Рәисе ярдәмендә **50** укытучыга максатчан квота бирелде. Киләсе елда Казандагы М14, «Салават Күпере» микрорайоннарындагы йортлардан тагын **150** фатир ачкычы тапшырылачак.

Фикер

Павел ШМАКОВ, Казандагы махсуслашкан олимпиада-фәнни үзәге – «СОлНЦе» мәктәбе директоры:

– Укытучыларның өметләре акланмады дип уйлыйм. Хәзер яңа электрон система кертеләчәк. Ул әле юньләп сынау үтмәгән, укытучының вакытын күп ала. Кәгазь эшен кыскарттылар, электрон формасы, киресенчә, артты. Бу тагын да начаррак. Бездә компьютерлар әйбәт, әмма интернет юньләп эшләми. Яңа системага күчәргә кирәкми, димим, әмма башта ул җайга салынган булырга тиеш. Укытучыларның күбесе өлкән яшьтә. Яшь укытучыларга ярдәм итү программалары бармак белән генә санарлык. Дәүләтнең ярдәме җитми. Укытучы елында конкрет гамәлләр кирәк иде. Әле менә концертка чакырдылар. Әмма укытучының тормышы аны карап кына яхшырмый бит. Хәлләрен җиңеләйтергә кирәк, тик бу әйбер юк. Укытучылар турында яхшы телевизион тапшырулар да булсын иде. Хезмәт хакын арттырырга кирәк. Мәскәү укытучылары 100 мең сумлап акча ала. Татарстанда хезмәт хакы – 30–50 мең сум тирәсе. Моның өчен 1,5–2 ставкага эшләргә кирәк. Безнең дәүләт фәкыйрь түгел бит. Инглиз теле, IT белгечләренең айлык эш хакы – 100 мең сум. Ә мәктәптә информатика, инглиз теле укытучысы 30 мең сум ала. Шуңа күрә вузларда бу юнәлеше тәмамлаган яшь белгечләр мәктәпкә укытырга бармый. Без 2019 елга кадәр ашханәсез яшәдек. Президент ярдәме белән булдырылды ул. Инде менә ничә елдан бирле спорт залы көтәбез.

БУЫП ЙӨТКЕРТӘ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казанда яшәүче 12 яшьлек Алсу Вәлиева әнисе белән бергә өч атнадан бирле сырхауханә юлын таптый. Кызның ютәле бетмичә азаплагач, табибка бара алар. Анда исә балага коклюш дигән диагноз куялар. Республика күләмендә андый хәлдә калучылар бихисап. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, хәзерге вакытта республикада 1290 кешегә коклюш диагнозы куелган. Бу узган елгы саннар белән чагыштырганда 160 тапкыр (!) күбрәк.

– Кызым ул көнне мәктәптән хәлсез кайтып керде. Кичкә инде борынына томау төште, аннары йөткерә башлады. Бер атна дигәндә кызымның ютәле көчәйде. Төнлә буылып уяна иде. Сырхауханәгә баргач, коклюш дигән диагноз куйдылар, – ди Алсуның әнисе Әминә.

Халык телендә бума ютәл дип йөртелгән коклюшның исеме җисеменә туры килә. Әлеге чирне йоктырган кеше буыла-буыла йөткерә, һава җитмәүдән зәңгәрләнеп үк чыга.

Казан дәүләт медицина академиясенең педиатрия һәм неонатология кафедрасы доценты Илдус Лотфуллин сүзләренә караганда, коклюшның артуы – бер яктан, табигый күренеш.

– Аның цикллары бар. Ул вакыт-вакыт күтәрелеп ала. Хәзер без чираттагы күтәрелеш циклына кердек. Әмма башка еллардан аермалы буларак, быел ул авыррак уза. Ник дигәндә, соңгы арада коклюшка каршы вакцина ясатырга теләмәүчеләр күбәйде. Нәтиҗәсе күз алдында: 2018–2019 елларда айга бер коклюш очрагы ачыклана иде. Быел әлеге чирне йоктыручылар саны берничә дистә тапкыр артты, – ди табиб.

Илдус Лотфуллин сүзләренә караганда, коклюш берничә стадиядә уза. Башта ул гадәти ОРВИ кебек җиңелчә

Коклюш турында кыскача

✓ Һава юлы белән күчә
✓ Беренче билгеләре бер атнадан күренә.
✓ Үпкә кабару, колак шешү, сукыраю, колак пәрдәсе ертылу, баш миенә кан саву, энцефалопатия, кендек турысына бүсер чыгу, көзән җыеру, эпилепсия өянәге, невроз кебек өзлегүләр китереп чыгара.

формада була. Аннары вакыт үтү белән ютәл спазмлы йөткерүгә әйләнә. Кеше йөткерә-йөткерә дә косып җибәрә. Кечкенә балаларның, йөткергәндә, сулышы туктарга мөмкин хәтта.

– Сулыш туктаганда, баланың баш миенә кислород җитми (гипоксия). Шуңа бәйле рәвештә организмда төрле өзлегүләр дә килеп чыгарга мөмкин. Араларында иң куркынычы – баш миенә кан саву. Шуңа күрә без, иң беренче чиратта, бәләкәй балаларны сакларга тиеш. Бигрәк тә яңа туган сабыйлар өчен куркыныч ул. Тәмәке тартучылар, астмадан интегүчеләр, 65 яшьтән узган кешеләр дә бу чиргә тиз бирешә, – ди табиб. – Коклюш – җил чәчәгеннән дә тизрәк ияргә торган йогышлы авыру. Шуңа күрә кулларны юып, битлек киеп йөрегез дигән гадәти киңәшләр генә бу чирдән саклап бетерә алмый. Коклюш йокмасын өчен, иң беренче чиратта, вакцина ясатырга кирәк. Бер яшькә кадәр балага – өч тапкыр, аннан – дүртенчесе, алты, ундүрт яшь тулгач, тагын ике вакцина ясала. Йөкле хатын-кызларга да өченче триместрда коклюшка каршы прививка ясатырга кирәк. Әнисе балага әлеге чиргә каршы иммунитет бирсен өчен кирәк бу.

Башкаланың 11 нче шәһәр балалар хастаханәсе табиб-педиатры Гөлназ Азизова сүзләренә караганда, прививкасыз бала, коклюш белән авырып терелгәч, киләчәктә гадәти ОРВИны да кыенрак уздырачак.

– Бума ютәлгә каршы прививкасы булган балалар коклюшны җиңелрәк уздыра. Вакцина ясалмаган бала чирне авыр кичерә, озак дәвалана, йөз көн дәвамында ютәлли, – ди табиб. – Бәхеткә, соңгы арада коклюш очраклары кими төште. Көз көне һәр өч баланың берсендә диярлек коклюш ачыкланды. Моңа күп кенә ата-ананың прививкаларга каршы булуы сәбәпче. Элегрәк елына 2–3 коклюш очрагы очрый иде, быел бер безнең участокта гына аена утызлап шундый диагноз куелды. Чирне бик авыр уздырган, хәтта башына кан сауган балалар да булды.

Авыл җирлекләрендә ул яктан тынычрак булып чыкты. Һәрхәлдә, «ВТ» хәбәрчесе элемтәгә кергән Питрәч районының Тау Иле, Саба районының Олы Шыңар авылларында коклюш йоктыручылар гомумән юк икән. Фельдшерлар моны вакытында прививка ясату нәтиҗәсе дип саный.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада кызамык һәм коклюшка каршы ясала торган вакцинага кытлык юк, алар барлык дәвалау оешмаларында да бар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КУРКУЛЫК КОЮЧЫ ИРЕК ХӘЗРӘТ:

«НАЧАРЛЫК КУРГАШТА КАТЫП КАЛА»

Кургаш белән куркулык коючылар турында әбиләремнән ишеткәнем бар иде. Элек-электән авылда моның белән шөгыльләнә торган әбиләр булган, аларның шактый кешегә ярдәме тигән, дип сөйлиләр иде. Казанда яшәүче Ирек хәзрәт Җәмалов та кургаш белән куркулык коя. Бу эшнең бик күп нечкәлекләрен, асыл мәгънәсен яхшы белә ул.

Кургаш белән куркулык коюның тәртибен әнисе ягыннан туганы өйрәткән аңа.

– Туганымның төшенә ап-актан киенгән бер әби кергән, куркулык коюның рәтен дә шул күрсәткән. Мин исә башта аннан карап өйрәнергә тырыштым, аннан, авырып киткәч, үзе барын да аңлатып калырга ашыкты, – дип сөйләде ул.

Ирек хәзрәт башкаларны өшкерә торган булган. Әмма, кешене дәвалыйм дип, үзе еш кына авырый, хәлсезләнә башлаган.

– Бервакыт миңа: «Кулыгыздан кайнар бәрә», – диделәр. Шунда мин уйлана башладым. Бер-ике кешене өшкергәннән соң хәлсезләнүемә дә аптырадым. Эзләндем, укыдым, бик күп дәресләр уздым. Баксаң, ул кайнарлык энергия икән. Ягъни мин, куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәмәгәнгә күрә, башкаларга үз энергиямне биргәнмен. Күп кенә хәзрәтләр шуның аркасында бу эштән туктады. Аннан соң, массаж ясаучылар да нәкъ шулай үзләренә чир җыя, – дип аңлатты Ирек хәзрәт.

Кургашка әйләнеп кайтсак, аның асылы менә нәрсәдә икән:

– Кургаш коюны диндә ярамаган гамәлгә санаучылар бар. Шикләремне бетерер өчен, бик атаклы дин белгеченә мөрәҗәгать иттем. Тыелган, ярамаган гамәлләр Коръәндә бик төгәл язылган. Шул ук вакытта Коръәндә менә шундый юллар бар: «...тимердә кешеләргә күп файдалар бар...» (Коръән: «Тимер» сүрәсе, 25 нче аять). Бу очракта «тимер» сүзе күпкә тирән мәгънәгә ия. Җир астыннан алынган тимерләр арасында кургаш химик составы буенча да, энергетика ягыннан да иң зур көчкә ия. Куркулык койганда ул авыру, зәхмәт һәм башкасын «суырып» ала. Һәм алар шул кургаш эчендә катып кала, – диде әңгәмәдәшебез.

Эретелгән кургашны суга салгач, анда курку чыганагының сурәте пәйда була. Ирек хәзрәт сүзләренчә, ул сурәтләрнең нәрсә аңлатканын «укый» белергә кирәк.

– Шайтаннар кургашта йөзләрен күрсәтә. Хәтта бозым ясаган кешенең йөзе шәйләнгән очраклар да була. Бик гади итеп әйткәндә, бар начарлык кургашка чыга, кеше чистарына. Ахырдан исә тагын бер кагыйдә турында онытмаска: ул кургашны агым суга ташларга я җиргә күмәргә кирәк. Әмма аңа синнән башка берәү дә кагылырга тиеш түгел, – дип сөйләде ул.

Хәзерге Татарстан гына түгел, бөтен Россиядән киләләр икән.

– Хәтта Казахстан, Кыргызстаннан да килүчеләр бар. Башка дин вәкилләре дә килә – аларны да кабул итәм. Миңа килгән кешеләрнең бүгенге халәтен, ул халәткә ничек, нәрсә аркасында килгәнен сөйләп бирәм. Күрәзәчелек белән бутамасыннар иде, бу – бөтенләй башка нәрсә, – ди ул.

Ирек хәзрәт ҖӘМАЛОВның кайбер кызыклы фикерләре

✓ Беренчедән, курку ул – иллюзия. Аллаһка ышанмаган кеше генә курка. Икенчедән, матди дөньяда курку юк. Ул синең башыңа кергән дә, энергияңне «суырып» утыра. Ачу, үпкә кебек хисләр белән дә шулай ук.

✓ Кеше үз-үзен дәвалый. Миңа мөрәҗәгать итә икән, ул миңа ышана. Аны шул ышану да дәвалый.

✓ 12 яшькә кадәрге баланың бөтен борчу-куркулары һәм башка зәхмәтләр әнисенә бәйле. Баласын карынында йөрткән чакта ниндидер проблемалары булса да, баласы тугач, аңа ачу белән караса да, баласына кычкырса, аның алдында әтисе белән талашса да – барысы да сабыйга йогынты ясый.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

P.S. Язма бу күренешне пропагандалау максатыннан түгел, ә күренеш буларак тасвирлау максатыннан язылды.

ФАҖИГАГӘ ЮЛЫККАН РАИЛ ГАЛИӘКБӘРОВНЫҢ ХАТЫНЫ:

«АРБАСЫН КҮРМӘДЕМ ДӘ»

Моннан 15 ел элек булган вакыйга Раил Галиәкбәровның тормышын икегә бүлә дә куя. Казан дәүләт энергетика институтының 3 нче курсында укып йөрүче егет юл һәлакәтенә очрап, гомерлеккә гарип кала. Авылларына кайтучы машина юл кырыена төшеп китә. Башка егетләргә берни булмый, ә менә Раил аңын югалта. Аны тизрәк Казан хастаханәсенә җибәрәләр. Егетнең башына, күкрәгенә, умырткалыгына зыян килә.

Ул чакта янәшәсендә әнисе Әнфисә апа була. Күпме генә катлаулы операцияләр кичерсә дә, Раилнең хәле уңайланмый. Ул бик нык ябыга. Шул чакта Шәмәрдән табибы Радик Борһанов егеткә массаж ясап карарга була. Раил шуннан соң тернәкләнеп китә. Үзе дә сизмәстән энисеннән ипи сорый һәм куллары ризыкка үрелә башлый. Әле кайчан гына берничнди хәрәкәтсез яткан егет өчен моннан да зур шатлык булмый. Әкренләп Раилнең яшәү теләге барлыкка килә. Ул ничек тә аякка басарга дип яши башлый. Йөртмәгән тернәкләндерү үзәкләре калмый. Район табиблары да ташламый аны. Коляскадан – диванга, диваннан коляскага күчереп утыру да тиңе булмаган бәхеткә әйләнә.

Тернәкләндерү үзәкләренең берсеннән ул өстәл теннисы белән мавыгып кайта. Өйләренә кайткач, әтисе белән уйный башлый. Башта куллар да тыңламыйча маташа әле. Әмма егет өчен артка юл юк. Ул ничек тә сынатмаска дип яши. Һәм максатына ирешә дә. Раил кул белән идарә итә торган машинага утыра. Куркуны җиңәргә өйрәнә, район эчендә йөри башлый. Соңрак Казанга, башка шәһәрләргә дә чыгып китә. Теннис буенча төрле бәйгеләрдә катнаша, Татарстан чемпионы исемен дә ала. Спорт мастеры да була. Россия буенча үткәрелгән ярышларда да сынатмый. Новгород, Брянск, Уфа, Тула, Санкт-Петербург калаларындагы турнирларда уйный. 2014 елдан халыкара ярышларда катнаша. Венгриядә – өченче, Франциядә команда уенында беренче урынны алалар. Россия җыелма командасы составында Даниядәге Европа Чемпионатында катнаша. Словениядә, Италиядә, Франциядә була.

– Аяклар йөрмәсә дә, кулларым эшли бит, – ди Раил үзе. – Иң мөһиме – югалып калмаска, бирешмәскә кирәк! Янәшәңдә яхшы кешеләр күбрәк булган саен, синдә ышаныч арта. Бик авыр чакларда әнием терәк булды. Хастаханәдә гел янымда иде. Минем өчен бөтен туганнарым борчылды. Аларга мең рәхмәт. Әни армасын дип, хастаханәдә чакта аны алыштыралар иде. Бар да яхшы буласына ышану яшәтте мине. Юлымда Лэйсәннең очравы да язмышымда зур бүләк булды.

Җыелы яңгыр булып килеп керә ул Раил күңеленә. Бер лагерьда шәфкать туташы булып эшләүче Лэйсән ярышка килгән егетне күреп ала. Шул мәлдә күзләр очраша. Беренче күрүдән алар бер-берсенә гашыйк була.

– Мин Раилнең коляскасын күрмәдем дә. Әйтерсең, ул юк. Аның зәңгәр күзләренә кереп югалдым. «Ярдәм итимме?» – дигәнем истә. «Әйдә, тупларны биреп тор», – диде ул миңа. Ярыштан соң Раил социаль челтәрләрдә мине эзләп табып, хат язды. «Очрашыйк», – дип язган. Мин дә каршы килмәдем. Шул ук көнне әнисе белән таныштырды. Бик ачык күңелле, кешелекле егет икән дидем, – дип искә ала Лэйсән. – Раил белән танышуым турында башта дөресен әйтергә курыктым. «Әни, мин бер егет белән таныштым, әмма ул йөри алмый», – дим. Әни мондый танышлыкка каршы килмәде. «Эчкече, наркоман түгел бит», – диде.

Яшьләр гөрләтеп туй ясый. Дөрес, баштарак Лэйсәннең колякскада утыручы егеткә кияүгә чыгуын аңлап бетермәүчеләр дә була. Әнисенә дә, үзенә дә, беткәнмени

Раил яшерми: Лэйсәненең яратуы аңа бар киртәләрне җиңәргә булышкан.

башка егет, дип килеп әйтәләр. Лэйсән өчен Раилдән дә яхшы ир-ат юк. Ул ялгышмый. Алар бер-берләрен аңлап, хөрмәт итеп яши башлый. Башта Раилнең әти-әнисе белән яшиләр. 2020 елда үзләренә йорт салып, башка чыгалар. Өйләрендә бар нәрсә дә Раил өчен көйләнгән.

– Раил белән очраштырган өчен язмышыма рәхмәтлемен. Ул – бик акыллы ир-ат. Һәр нәрсәне тыныч кына хәл итә. Миңа төпле киңәшләрен бирә. Гаиләдә ир-ат нинди эш башкарса, шуны эшли. Мин йөри алмыйм, дип утырмый, яңа йорт салып чыккач та, барлык эчке эшләрне үзе башкарды. Раил – миңа бик зур терәк, – ди Лэйсән.

Лэйсән инде тугыз ел үз районнарында һәм якынтирәдә сабыйларга бәйрәмнәр оештыра. Һәр чарага әзерләнгәндә Раилдән киңәш сорыйм, ди. Раиле дә ерак юлга үзен генә чыгарып җибәрми икән. Аеруча кыш көннәрендә. Тирләп-пешеп бәйрәм уздырганнан соң, җылы машинага чыгып утыр, дип көтеп тора икән. Бер карасаң, вак кына әйбер кебек. Әмма гаиләне тулы итү җылы сүздән, сиңа булган мөнәсәбәттән дә тора бит! Раил дә яшерми: Лэйсәненең яратуы аңа бар киртәләрне җиңәргә булышкан. Алар бүген Сәлим һәм Салават исемле ике ул үстерә.

> Мин Раилнең ышыгында яшим. Ул ир-атның барлык яхшы сыйфатларын үзенә җыйган. Аның белән миңа бик рәхәт. Таянырлык кешем ул, – ди Лэйсән.

Раил бәхетле яшәүнең серләрен дә ачты.

– Вакчыл булмаска, кайбер нәрсәләрне күрмәскә, ишетмәскә кирәк. Тәлинкәләр ватып, өйдән чыгып китеп тавышланган юк. Бер-ике минутка әләгешеп алабыз инде без. Әмма аны тиз онытабыз. Иң мөһиме – бер-беребезгә ышанып, хөрмәт итеп, яратылып яшибез. Тормышта нинди генә хәл булмасын, язмышыңны кабул итеп яшәргә кирәк. Бәргәләнүдән ни файда?! Бирешмәскә, сынауларны җиңәргә өйрәнергә кирәк. Һәм ышанырга. Тереләсеңә, бәхетле буласыңа ышанырга кирәк!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

«Композитор» Ринат

Социаль челтәрләрдә өздереп баян уйнаган һәм шуңа кушылып җырлап утырган ир-ат видеосына тап булдым. Күңелне айкатып, йөрәк түрени үтеп җырлый. Аның йөзе дә елмая, кашлары да бии, кыскасы, үзеннән нур бөркелә. Күңелгә шулкадәр үтеп керде бу кеше. Кем икәнен тиз белдек. Казанда яшәүче бакчачы Рәмзия Әхмәдуллинаның икетуган абыйсы Ринат Гыйниятов икән.

– Безнең абый кебек кеше юк. Гомере буе заводта эшләде, әмма кулыннан баяны төшмәде. Матур җырлый. Кушаматы да «Композитор» аның. Ул бөтенебезгә дә үрнәк, терәк. Язмыш сынауларына да бирешмәде, – диде Рәмзия.

Ринат абыйның үзен өйдә туры китерә алмасак та, хатыны Рәшидә белән сөйләшергә насыйп булды.

– Ирем белән соң гына кавыштык. Ул чакта миңа 38 яшь иде. Шөкер, бик матур итеп 32 ел бергә гомер итәбез. Бер ул үстердек. Бер-беребезне аңлап, санлап яшибез. Ринат – бик тыныч кеше. Беркем белән дә талашып йөрми, гел булышырга гына тора. Бик тә туган җанлы, – ди хатыны. – Бер ел элек гаиләбезгә зур сынау килде. Уйламаганда ирем авырып китте. Тәнендә шеш барлыкка килде. Шундук табибка күренергә киттек. Безне Казан онкология диспансерына җибәрделәр.

Табибның бик яхшысы туры килә аларга. Тик анализ нәтиҗәләре сөендерми – Ринат абыйга яман шешнең 3 стадиясен куялар. Иреннән бигрәк Рәшидә апа сыгылып төшә.

– Ринатымны югалтам икән, дип кайгырдым. Әле бит яши генә башлаган кебек идек. Улыбызны өйләндереп, аның балаларын сөясе килә. Матур картлыкны бергә үтәсебез бар! Күп еллар фельдшер булып эшләгән дәү апам үзенең киңәшләрен биреп, мине тынычландырды. Шуннан соң үземне кулга алдым. Бар көчемне Ринатымны дәвалауга бирәм. Ирем 8 химия терапиясе алды. Гел янәшәсендә булдым. Бу чир белән очрашкан кешеләрнең киңәшләрен тыңладык, табиблар кушканны үтәдек, – ди Рәшидә апа.

Бирешә чир, артка чигенә. Табиблар да сөендерә. Ринат абыйның хәле уңайланып китә, ул эшкә дә чыга. Әмма әле вакыт-вакыт табибларга күренеп, анализлар тапшырасы икән.

– Без Ринат белән спортны үз итәбез. Ул 50 яшеннән гер күтәрә. Бергә бассейнга йөрибез. Сынаулар алдында сыннарга сәламәт яшәү дә булышты дип уйлыйм, – ди Рәшидә апа. – Ринат гомере буе кулыннан баянын төшермәде. Заводта үткән һәр чарада уйнап җырлар иде. Хәзер дә бер генә мәҗлес тә ансыз узмый. Әле менә Ринат терелүгә шөкер итеп, Коръән ашы уздырдык. Ирем барлык туганнар алдында миңа рәхмәтен җиткерде. «Рәшидә булмаса, терелә алмас идем», – диде. Ә мин ул булмаса, яши дә алмас идем. Язмышыма юлымда Ринатымны очраткан өчен рәхмәтлемен. Әле тагын озак еллар тигезлектә яшәсәк иде.

МӘДИНӘ МАЛИКОВА:

«КӨЧӘНЕП ЯЗГАН ӘСӘРЛӘРДӘН ТИР ИСЕ КИЛЕП ТОРА»

Татар әдәбиятында хатын-кызлардан беренче романист. Кискен фикерен кистереп әйтүче. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Таныдыгызмы? Сүзебез – Мәдинә Маликова турында. Язучы ничек көн күрә? Үзеңне ничек тонуста тотарга? Китапны халыкка җиткерүнең нинди юллары бар? Китап сатып, тормышны алып барып буламы? Тугызынчы дистәсен тутырып килүче язучы белән әнә шул сорауларга җавап эзләдек.

:: Бүген 18 яшьлек Мәдинәгә нинди киңәшләр бирер идегез?

– Киңәшләрне мин үз-үземә яшьтән үк дөрес биргәнмен булып чыкты. Авылыбызда җидееллык мәктәпне тәмамлап, кулга мактау кәгазе алгач, мин Чаллыга барып, пароходка утырып, аның палубасындагы мичкәләрнең берсе өстендә төннәрен йоклый-йоклый, Казанга киттем. Укытучылар әзерли торган югары уку йорты якын гына, Алабугада да бар иде барын, әмма минем күңелем еракка ашкынды, биеккәрәк омтылды.

:: Сез, китап сатып баеп була, дип әйткән беренче язучы да әле. Ничек яшисез, баедыгызмы?

– Язучылар арасында мин хәллеләрдән саналам. Һәрхәлдә: «Яңа роман язган идем, шуны китап итеп бастырып чыгарырга ярдәм итмәссезме икән?» – дип, беркем каршында да йөз суы түгеп басып торганым булмады. Хәзергечә әйтсәк, спонсорларым юк. Бурычка да батмадым. Татарстан китап нәшриятында мине, кайчан килсәм дә, ачык йөз белән каршы алалар, романнарымның, гомумән әсәрләремнең берсен дә яраксыз дип бәяләгәннәре юк, рәхмәт аларга. Табигый ки, алар алдан расланган план буенча эшлиләр.

> Мин исә кайчакта сабырсызланам, тәмамланган күләмле әсәремне шундук китап хәлендә күрәсем килә. Андый очракта китапны үз хисабыма бастырып, тиражын өемә кайтарып тутырып, аннары машина яллап, кибетләргә тарата идем.

:: Күләмле әсәр язу өчен хәтернең дә шәп булуы кирәк бит әле. Хәтер өчен ниндидер махсус күнекмәләр ясыйсызмы? Спорт белән дуслык ничек?

– Ял иткәндә кроссвордлар чишәм, иртән физик күнегүләр ясыйм. Шахматны күптән ташладым, студент чагымда институт чемпионкасы идем югыйсә. Вакытны күп ала торган шөгыль бит ул. Яңа әсәр язарга тотынгач, шахмат уйнап утыра алмыйсың. Ә йөзәргә мин бик ярата идем. Кубага баргач, Кариб диңгезендә, Атлантик океанда йөздем, Японияда сәяхәт иткәндә – Тын океанда. Безнең бакчабыз Казансу буенда бит. Җәйге эссе көннәрдә сәгатьләр буе судан чыкмый идем. Сиксән яшемә хәтле ярыйсы гына йөзә идем әле. Тик соңгы елларда безнең бакча янында Казансу саекты, ләмләнде, биздерде, башка урынга барырга күңел тартмады. Шактый еллар йөзгән юк инде.

:: Беренче гонорарыгызны хәтерлисезме? Аны нәрсәгә тоттыгыз?

– Аны онытып буламы? Өченче курска күчкән идем инде, гел «бишле»гә укыйм, югары стипендия алам, әмма туйганчы ашап булмый, акча җитми генә бит! Эш эзләргә ниятләдем, якындагы тегү фабрикасына барган идем, син булдырырлык эш юк бездә, диделәр. Шуннан киттем мин институтның комсомол комитетына. Анда мине яхшы беләләр иде, чөнки бик актив идем. Хәтердә: алар мине «Белем» җәмгыятенә җибәргәннәр иде, анда исә институтның бер кичәсендә доклад сөйләргә тәкъдим иттеләр. Бушка, билгеле. Мин шуны да эшләдем бит әле. Бу юлы исә: «Яшь сталинчы» газетасының редакциясенә барып, Бикжанова белән сөйләш әле син», – диделәр. Бардым, күрдем, сөйләштем. «Институт тормышыннан бер мәкалә язып китерсәң, яхшы булыр иде», – диде ул миңа. Яздым, илтеп бирдем. Ике көн үткәч, иртән радио тыңлый идем, газеталарга күзәтү тапшыралар. Шунда үз исемемне ишеткәч, куанычымның чиге булмады. Кулга гонорарын алгач сөенү тагын! Әлбәттә инде, институтның ашханәсендә туйганчы ашадым.

:: Быел биш томлылыгыз дөнья күрде. Бу сезнең өчен нинди вакыйгага?

– Татарстан китап нәшриятында күптән инде ун томлыгым планлаштырылган иде. Ул арада томнарны нәшер итү өчен Фәннәр академиясенең хәер-фатихасы кирәклеге беленде. Андагы галимнәр, Маликовага биш томлык та бик җиткән, дигән кебегрәк язып җибәргәннәр булса кирәк. Минем үзем белән сөйләшүне кирәк дип санамадылар, билгеле. Ни генә булмасын, аларның сүзе өскә чыкты. Кагыйдә буларак, томлыкларга язучының бар булган иҗаты тулаем туплана торган булса да, миңа кагылгач, ул тәртип бозылды. Повестьларым, хикәяләрем, пьесаларым, мәкаләләрем, зур галимнәрнең минем әсәрләрем турында язган саллы мәкаләләре, күренекле шәхесләрдән килгән хатлар, Мәскәү нәшриятларыннан җибәрелгән рецензияләр – берсе дә ул китапларга сыймады. Минем иҗатым турында пединститут аспиранты Лилия Хисмәтова кандидатлык диссертациясе яклаган иде. Аның аннотациясенә дә урын бирелмәде.

Моңа минем эчем пошты, билгеле. Әмма томнар кулга кергәч, күңел күтәрелде, авыз ерылды – сөенеп туймыйм. Алар шундый матур, бертөрле кебек тә үзе, әмма һәркайсы аерым бертөсле. Һәрберсеннән җан җылысы бөркелә сыман. Мең рәхмәтләр укыйм Татарстан китап нәшриятының баш редакторы Ленар Шәехка. Томнарымны бастырып чыгарыгыз әле, дип гариза язарга батырчылык итмәс идем, ул тәкъдим итте.

:: Иң катлаулы әсәр дип романнарыгызның кайсын атыйсыз?

– Әлбәттә, беренчесен, «Шәфкать»не. Озак язылды. Әмма басылып чыккач, искиткеч яхшы бәяләнде. Миңа бик күп хатлар килде, режиссер Әхтәм Зарипов аның буенча дүрт серияле телевизион тапшыру эшләде, ул телевизордан күп тапкырлар күрсәтелде...

:: Язучы ялгызлык ярата, диләр, дөресме?

– Язучының тәрлесе бар бит. Ике улым да мине күп сөйләшәсең дип тәнкыйтьлиләр. «Тел тегермәнем гел тартып тормаса, ни ашар идем?» – дип җавап бирәм. Ә бит, мин такылдаганны берәү генә булса да тыңласын иде, дип телисең. Ялгызны кем ишетә?

:: Мәдинә апа, гадәттә, язучының гаиләсе, балалары да күз уңында була. Гаиләдән уңдыгызмы, балаларыгыз өметләрегезне акладымы?

– Зур өметләр баглый идем, дип әйтә алмыйм. Яхшы укысыннар, эшкә остарсыннар, дип тырышасың инде ул. Ике улым да университет тәмамладылар, программистлар. Олысы Ильясны кечкенә чагында ук шахмат уйнарга өйрәткән идем, чөнки үзем институтта укыган чагымда – беренче булган кеше. Ул бу шөгыль белән нык мавыкты, Татарстан суверенлыгын игълан иткәннән соң мәмләкәтебезнең беренче чемпионы булганлыгын горурланып искә ала.

:: Ирегез, шагыйрь Әхмәт абый Рәшитнең бакыйлыкка күчкәненә дә шактый вакыт узды. Сагындырамы? Ул нинди ир иде?

Блиц сораштыру

– Иң зур курку?
– Ач калу. Балачактан бәгырьгә сеңеп калган.
– Иң зур теләк нинди?
– Сау-сәламәт булу.
– Нинди тема, бәлки жанр сезгә катлаулы булды?
– Драматургия... Шигърият... һәм башкалар, дияр идем мин. Барча жанрларда да зур уңышларга ирешкән каләм иясен белмим мин. Әдәбиятның мәйданы яшәешнең үзе кебек үк чиксез, аны колачлап бетерү адәм баласының көченнән килмидер.
– Адәм баласы гомерен туган көннәре белән саный. 88 яшьтә нинди сабак яки сынаулар узасыз? Бу ел сезнең өчен нинди ел булды?
– Сынаулар дигәне, Аллага шөкер, булмады. Ел гадәттәгечә узды: язны, җәйне, көзне бакчада хозурланып һәм булдыра алганча эшләп уздырдым, кыш җиткәч, компьютер каршына утырдым.
– Бәхетле булу өчен хатын-кызга нәрсә кирәк?
– Һәр кешегә, ирме ул, хатын-кызмы, иң беренче чиратта кирәк нәрсә ул – исәнлек-саулык. Аннары эшеңнән уңу. Үзеңә тиң яр – пар табу. Кеше башына хәсрәтләр килә, берәүнең дә капчыгы буш түгел, диләр халыкта. Кайгыларны күтәрергә күп сабырлыклар кирәк. Башымны ташка орырдай чакларым бар иде минем дә. Бүген исә мин үземне бик бәхетле дип саныйм һәм хис итәм. Үз аягымда йөрим, теләгәнемне ашыйм, үз-үземне карыйм. Һәм һаман да каләмемне тибрәтәм. Шөкрана итеп туймыйм.

– Җырларда җырланганча, сагынмаган кая ул, дияргә генә кала. Без кырык биш ел бергә яшәдек. Билгеле инде, төрлесе кичте баштан, өйдә савыт-саба шылтырамый тормый, диләр бит. Әрекмән кәбестә түгел, адәм фәрештә түгел, диләр тагын. Әмма хәзер инде кайчандыр үпкәләшкән, ачуланышкан минутлар хәтердән юып алынган. Минем хәтеремдә ул гел елмаеп тора сыман.

:: Язучы булам дип хыялланган кешегә нинди киңәшләр бирер идегез?
– Җырлый-җырлый, бии-бии языгыз, дияр идем. Язу сезнең өчен бәйрәм булсын. Тырышып-тырмашып, көчәнеп язган әсәрләрдән тир исе килеп тора, минемчә. Һәр тавык алтын күкәй генә салып тормаган кебек, каләмнән кәгазьгә өзелеп төшкән һәр сүз асылташ була алмас, билгеле. Ул хакта уйлаганда, мин Маяковскийның шигырен искә төшерәм: «Асылташка тиң бер сүзне эзләп, буш сүзләрнең табын актарам». Анысына күнегергә кирәк.

:: Быел нинди әсәр языла башлады?
– Хәзерге вакытта яңа әсәр язуны үземә бурыч итеп кую дөрес булмас, дип уйлыйм. Аның өчен йөрәкнең җилкенүе, акылның үткенлеге кирәк, дип исәплим. Соңгы елларда романнарымны рус теленә авыштыру белән шөгыльләнәм. Ике китап әзерләп бастырдым иде, берсе хәтта ел китабы дип бәяләнде. Менә хәзер өченчесен әзерлим.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВ

ӨЯНӘК

(ХИКӘЯ)

Миңнулланың тәмам йокысы качты. Болай да тынгысыз кеше иде, хәзер бөтенләй пырдымсызга әйләнде. Хәтта аның холкын күптән өйрәнеп, шуңа буйсынып яшәгән карчыгы Фәнүсә дә моңа шаклар катты. Әйтерсең әллә кайда калган яшь чакларына, өйләнешкән генә вакытларына әйләнеп кайтканнар.

Ул чорда иренең дуамаллыгына бик зур авырлык белән ияләшкән иде. Баштарак, бу мине тәмам яратмый инде дип, төннәр буе елап чыккан чаклары да булды. Чүпрәк-чапракларын җыештырып, әнисе янына кайтып китәргә дә уйлады. Аннан соң күнекте тагын. Миңнулланың үз-үзен тотышында бер генә явызлык та юк, шундый итеп яратылган. Тоз түгелсә, өянәге кузгала, ипи валчыклары өстәлдә таралып ятса, кара тавыш чыгара... Тәртип ярата Миңнулласы, бары шунда гына бөтен сәбәп. Яши-яши әллә Фәнүсә күнде, әллә ире басыла төште... Һәм менә яңадан Миңнулла элеккеге халәтенә әйләнеп кайтты шикелле.

Миңнулла – бик тырыш, гаиләле җанлы, булдыклы ир. Алар икесе дә – авылда туып-үскән кешеләр, Казанда институтта укыганда таныштылар. Фәнүсә аны беренче караштан ук ошатты. Төпле, килде-китте сүз сөйләмәс, теләсә кайсы эшнең җаен белә.

Мәхәббәт тарихларын сөйләп тору артык булыр – андый кыйссалар Җир йөзендә миллионнарча мәртәбә кабатланган. Бернинди гайре табигый, үтә дә романтик, бот чабып гаҗәпләнерлек борылышлар булмады анда. Таныштылар, яратыштылар, йөрештеләр, өйләнештеләр. Балалары туды, һәрбер гаиләдәгечә, шатлыгын да, хафалы чакларын да күреп, аларны үстереп, аякка бастырдылар.

Гаилә тормышы да башкаларныкы төсле. Төрле чаклары булды: талаштылар да, сөештеләр дә. Кыскасы, тотып селкерлек бер генә вакыйга да истә калмаган. Балалары үсте, кайсы кая таралышты. Миңнулланың тырыш хезмәте белән эшләп алынган өч бүлмәле фатирда, кайчандыр затлы саналган стенка, диваннар, киштәкиштә тезелешеп, тузан җыеп утыручы китаплар арасында алар икәү генә яшәп калды.

Тормышлары зарланырлык түгел, җайлы гына акты. Фәнүсә инде пенсиядә, Миңнулласы гел эшләп йөри. Гомер буе бер конторада. Иртән тора, бик җентекләп кырына. Төсе уңып, җиң очлары туза башласа да, килешле генә күренгән шакмаклы күлмәген үтүкли, туксанынчы елларда моданың соңгы чиге саналган галстугын тага, терсәкләре шәлперәебрәк торган кәчтүмен кия дә эшенә ашыга. Фәнүсә аны көтә кала, көн дәвамында оныклары янына барып килергә дә өлгерә, кичен исә табын хәстәрләп, картының эштән кайтканын көтеп тора.

Кич алар табынга бергә утыралар. Миңнулла атнага бер, һичшиксез, итле аш ашарга күнеккән. Әле анысы да тана ите булсын. Артык майлы да ярамый, бөтенләй майсыз икән – тамагыннан үтми, коры. Сирәк кенә тавык шулпасына да риза, тик җыен бройлерфәлән түгел, авыл тавыгына тартымрак коштан пешерелсен. Эре итеп туралган башлы суган, бер тырнак сарымсак. Миңнулла кичке ашын алардан башка күз алдына да китерми. Җомга кичендә өйдә таба исе чыкмаса, хатыны белән якшәмбе иртәсенә кадәр сөйләшмәячәк. Өстәлдә балның өч төрлесе – анысын ире, кәефенә карап, чәй эчкәндә аз гына кабып куйгалый. Бик кәефле көннәренең билгесе – кәрәзле бал белән чәй эчү.

Фәнүсә Миңнулланың бөтен бу гадәтләренә күптән күнегеп беткән иде. Нәрсәне ничегрәк әзерләргә, кайсы сүзне кайчан әйтергә ярый, кайда дәшми калырга кирәк – болары да дистә еллар дәвамында үзләштерелгән сабаклар. Тормышлары көйле генә бара иде кебек. Кичке аш, телевизор карау, айга кимендә ике тапкыр концерт-театрларга йөрү, җәй көннәрендә ялларны Таулар бистәсендәге бакчада казынып үткәрү, әллә нигә бер балалар, оныклар белән күмәкләшеп очрашу... Матур гына яшәп ятабыз дигәндә, Миңнулланы алмаштырып куйдылармыни?!

Ире әллә ничек кыбырсый башлады, юктан гына да дөрләп кабына, тузып китә, күзләрен акайтып карый. Фәнүсә, картының мондый хәтәр халәтен аңлар өчен, юмалап та сөйләшеп карады, ачуланган да итенде, тик барыбер Миңнулланы чыгырыннан чыгарган сәбәпне ачыклый алмады. Ул биргән сорауларга тегесе, ысылдап: «Синең эшең түгел, кысылма!» – дип кенә җавап кайтарды.

Ә көннәрнең берендә, телефоннан гына шалтыратып: «Бүген соңрак кайтам, югалтма», – дип кисәтте. Фәнүсә бөтенләй коелып төште. Болай әйтүе иренең читтә берәрсе белән салырга җыенуын аңлата.

Салу килешми аның Миңнулласына. Андый мәҗлесләрдән соң төн буе йоклый алмый укшып чыга, икенче көнне башы, бөтен дөньясы авыртудан зарлана, кичкә кадәр адәм рәтенә керә алмый интегә. Үзе дә моны аңлый, әмма сирәк кенә булса да, тәртәдән чыгып ала шул. Торган саен сирәгрәк үзе.

Тик бу юлы башына нинди кайгы төшкәнлеген дә белеп булмый бит әле... Юраганга юш килә, начар уйларны куарга тырышып, Фәнүсә кибеткә чыгып китте. Иренә махмырдан сусавын басар өчен унҗиденче нумерле «Ессентуки» алып керергә кирәк...

Миңнулла карчыгына соңрак кайтуын әйткәч тә, тизрәк телефонының кызыл төймәсенә басарга ашыкты. Фәнүсәнең күпсанлы начар гадәтләре арасында теңкәсенә аеруча тигән берсе бар. Соң кайтуын хәбәр итсә, «Ник соңарасың? Кая барасың? Ничәдә кайтырга? Аш пешереп торыйммы?» дигән төсле тинтәк сораулар белән җаны актарып бетерә. Бүген аның белән озаклап сөйләшеп торырга тамчы гына да теләге юк. Соңгы вакытта үзен эчтән кимергән корт корсагын тишеп чыга бугай инде. Төн йокыларын, ашаган ризыкларының тәмен тартып алды шул корт.

Ул, түземлеге төкәнгәнлегенә оялса да, кул сәгатенә күз төшерде. «Командирский» сәгате кичке алты туларга биш минутны күрсәтә иде. Эш көне тәмамланырга биш минут вакыт калган. Үзе утырган зур бүлмәне күздән кичерде. Башкалар алтынчы яртыда ук таралышып бетте. Төгәллек белән килеп, нәкъ үз вакытында китүче бер ул гына. Өстәленә күз салды. Барлык документларны да эшкәртеп бетерде, бүген кергән кәгазьләрне иртәгә калдырмады – гадәте шундый. Гомумән, тәртип аңарда. Күршедәгеләрнеке төсле түгел. Эшләренең рәте-чираты юк, өсле-өсле папкалар өелгән. Яшьләр...

Аның бу тырышлыгын күрәләрме икән соң?! Тиешенчә бәясен бирәләрме?! Кирәк икән, кәгазь документларны ерып чыга, кирәк икән, кампитрга кереп, Дәүләт хезмәтләре порталын аркылыга-буйга иңли...

Дәвамы бар >

КОТЛЫЙБЫЗ!

8 декабрьдә кадерле әтиебез **ДМИТРИЕВ Николай Ильич**ның 86 яшьлек туган көнен бәйрәм итәчәкбез.

Әтиебез – Россиянең хезмәт ветераны, Балык Бистәсе районының почётлы гражданины. Ул Казак Чаллысы авылында гомер кичереп, озак еллар дәвамында авыл советы рәисе булып эшләде, аңа кадәр дә инженер һәм икътисадчы кебек җаваплы вазыйфаларны башкарды, алны-ялны белмичә эшләп, авылыбызда хөрмәт казанды.

Яраткан әтиебез! Сиңа нык сәламәтлек, бәхетле мул тормыш, көтелмәгән шатлык-куанычлар, балаларыңның игелеген, кадер-хөрмәтен күреп яшәвеңне, һаман да шундый көчле рухлы, тырыш һәм ярдәмчел булып калуыңны телибез. Туган йортыбызның яме булып, озын гомер кичерергә язсын! Әни белән безне яратып үстерүегез, зур тормыш юлына нык адымнар ясарга ярдәм итүегез өчен сезгә зур рәхмәт!

Иң изге теләкләр белән, уларың Анатолий һәм Михаил, киленнәрең Люба һәм Эльвира, киявең Коля, 7 оныгың һәм 3 оныкчыгың исеменнән кызың Зоя

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язып

4–14 декабрь –
ташламалы бәядән язылу көннәре

П2435 (җомга) >> ~~571 сум 98 тиен~~ **497 сум 34 тиен**

П2409 (сиш., чәрш., җомга) >> ~~1255 сум 86 тиен~~ **1086 сум 18 тиен**

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040

info@vatantat.ru

420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз ияс ачыклана.
14 декабрьдә уйнатылачак бүләк –
АЛЬБИНА ФАЗЛЫЕВАдан ПАЛАНТИН

Бу атна җиңүчесе – Биектау районы Ямаширмә авылыннан Раидә Сибгатуллина. Котлыйбыз һәм элемтәгә чыгуыгызны үтенәбез!

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

Беләсең килсә...

1 «Бер мең күл иле» дип кайсы дәүләтне атыйлар?
а) Финляндия;
б) Аргентина;
в) Индонезия.

2 Җырчы Егор Кридның чын фамилиясе:
а) Тимуркин;
б) Артуркин;
в) Булаткин.

3 Лунула нәрсә ул?
а) тырнак башындагы ярымай;
б) йолдызлыктагы иң якты йолдыз;
в) керфекләр кайчысы.

4 Җырчы Илназ Баһның туган ягы:
а) Балтач;
б) Арча;
в) Кукмара.

Җаваплар: 1. а); 2. в); 3. а); 4. б).



Әз-мәз мәзәк

– Ни өчен җырчылар рәссамнарга караганда күбрәк?
– Җырны тыңладың да оныттың. Ә рәсемнәрне каядыр өеп куярга кирәк.

***

Элек без видеоэлемтә турында фантастик кинолардан гына күреп хыяллана идек. Бүген берәрсе видео аша шалтыратса, исәрләнгән мәллә бу дип уйлап куябыз.

***

– Бүген циркка барабызмы?
– Юк, яңалыклар гына карыйбыз.

***

Иреңнән акчаны сорап алма. Сиңа акча бирергә рөхсәт иткән кыяфәт ясә.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: чирек, Бора, Арамис, рафинад, чак, ит, мә, им, Кирам, ямау, әби, инәй, аз, чи, Айнур, егу, ел, Нәс, зат, үт, Ив, ат, Фидан, савыт, Рәшә, Ту, Зара.

Вертикаль: чыршы, иярчен, Ост, МММ, игәү, ау, Рафинә, АИ, устав, куна, тыз, кан, әй, та, Ра, Рейн, БАД, Ира, Ом, чишмә, Резидә, Ризат, ба, лаваш, ас, Луиза, нәп.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13596 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 363

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+